Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 36 (1401) 16 сентябрь 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8

Казанга терәлеп кенә торган бай тарихлы Лаеш төбәгендә гаҗәеп тырыш халык гомер кичерә.

12

Сөйли башласа, авызына карата, баянын тартып җырлап җибәрсә, сәхнә «йолдыз»ларын көнләштерә ул – Алмаз Хәмзин!



14

Чаллыдан Фәһим Җиһаншин тырышлыгы нәтиҗәсендә дөньяның иң зур аңлатмалы аудиосүзлеге татар теле белән баетыла.

Калебләргә шифа биреп торсын Мөселманча кино сәнгате дә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- «Казан ярминкәсе» территориясендә мөселман әдәбияты фестивален; бизнес-форумны; хәләл продукция экспозициясен берләштергән «Ислам нуры» мөселман мәдәнияте күргәзмәсе узды.
- Татарстан Мәдәният министрлыгы И.Шакиров исемендәге республика премиясенә дәгъва итүчеләрдән гаризалар кабул итә.
- Ш.Закиров исемендәге «Идел-йорт» XXII театр коллективлары төбәкара конкурсы спектакльләре 7, 8, 9, 10, 16, 22 ноябрьдә Казанның Ленин исемендәге мәдәният сараенда күрсәтеләчәк.
- Алабугада рәссам Иван Шишкинның портретын чыршы күркәләреннән ясаганнар.
- Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Дагыстанда Рәсүл Гамзатов истәлегенә багышланган «Ак торналар» халыкара шигырь фестивалендә катнашты.
- Апас районы Түбән Барыш авылында Татарстанның атказанган артисты Асия Хәйруллина музеенда актрисаны искә алуга багышланган очрашу узды.
- Екатеринбургта узган «Петрушка великий» фестивалендә Илгиз Зәйниев «Иң яхшы режиссер эше» номинациясендә җиңү яулады.
- Башкортстанда мәгърифәтче һәм дин эшлеклесе Габдулла Сәединең ике зур китаптан гыйбарәт XIX гасыр кульязмалары табылган.
- Казан федераль университетының Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты галиме, «Сәләт» хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе Равил Һади вафат булды.
- Мөселман киносы фестивале кысаларында Татарстан Милли китапханәсендә Ренат Ибраһимовны искә алу кичәсе узды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Марсель ГАЛИЕВ, Татарстанның халык язучысы:

"Ватанга тугрылыкны Муса Җәлил кебек шигырьләр белән язган кеше башка халыкта юк бугай. Аны бик озак еллар күтәрмичә тордылар. Мин моны көнләшү дип тә карыйм. «Нигә татарда бар, бездә юк» дигән көнчелек булгандыр. Фронтовиклар күтәреп чыкмаса, булмас та иде. Татар халкы андый батырлыкка генетик яктан әзер".

СЫНАМЫШЛАР

22 сентябрьдә черкиләр күренсә, кыш җылы килә ● Сентябрьдә кар күренсә, көз озакка сузыла ● Агач яфракны соң койса, ел авыр килә ● Көз көне кошлар түбән очса – кыш салкын, югары очса – җылы килә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 16 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 59 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 43 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **23 сентябрьдә 12 сәгать 10 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

17 сентябрь – театр рәссамы, Татарстанның халык рәссамы Усман Нәҗметдин улы Абдулловның тууына 100 ел (1922–2010).

18 сентябрь – җырчы, конферансье, язучы-сатирик, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Наил улы Хәмзинга 75 яшь (1947);

– шагыйрә һәм прозаик, филология фәннәре кандидаты Рифә Фәтхрахман кызы Рахманга (Харрасова) 60 яшь (1962).

19 сентябрь – шагыйрь, тәрҗемәче, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нури Газиз улы Арслановның тууына 110 ел (1912–1991).

20 сентябрь – актёр, режиссёр, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Камил Шакир улы Вәлиевкә 80 яшь (1942).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 16, 22 сентябрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(18-26 сентябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген сәфәр аеның 20 нче көне

Көн кадагына

Зур экранда – дөнья сулышы



Казанда булып узган XVIII Халыкара мөселман киносы фестивалендә тамашачыларга 44 илдә төшерелгән иллеләп кинофильм, шуңа өстәп, бәйгедән тыш тагын шуның кадәр кинокартина карау мөмкинлеге тудырылды. «Милли бәйге» номинациясендә үзебезнең режиссерларның унлап фильмы катнашты. Кино сөючеләр танылган режиссер, фестивальнең биелгы жюри рәисе Владимир Хотиненко, кино йолдызы Наталья Варлей, актриса Олеся Судзиловская, актер Тимур Гарәфетдинов һ.б. белән очрашу бәхетенә ия булды. Фестивальнең «Республика» сәүдә үзәге кинотеатрына күчеп, чираттагы тапкыр урын алмаштыруы аркасында, андагы заллар элеккегеләре белән чагыштырганда кечерәк булу сәбәпле, кайбер фильмнарга, әйтик, "Ибн Фадлан"га бөтен тамашачы сыймый калгач, аны ике көн биш залда күрсәтергә туры килсә дә, үпкәләүчеләр булмагандыр, чөнки оештыручыларның һәр мәсьәләдә килешеп эшләүләре сизелә иде.

«Ибн Фадлан»

Айназ Мөхәммәтҗанов һәм Рәмис Нәҗмиев төшергән «Ибн Фадлан», тарихчыларның, дин галимнәренең чыгышлары белән үрелеп барган фәнни-популяр жанрга караса да, тамашачыларда зур кызыксыну уятты. Татарстан Диния нәзарәте рәисе Камил Сәмигуллин уйнасын да, кызыксынма, имеш. Хәер, хәзрәт төп рольдә түгел, Ибн Фадланны Тинчурин театрының талантлы артисты Зөлфәт Закиров гәүдәләндерә. Татар кинолары зур экранга сирәк чыгып, артистларыбызда халыкара фестивальләрдә экраннан күренү мөмкинлеге бик сирәк эләккәнгә, ахры, халык кинотеатрга ябырылып килде. 921 елда Багдад илчелегенең Болгарга сәяхәте нәтиҗәсе буларак ерак бабаларыбызның ислам динен рәсми кабул итүләре турында әлеге фильм лаеклы рәвештә фестивальнең зур әһәмияткә ия тарихи вакыйганы гәүдәләндергән өчен махсус дипломына лаек булды. Хәер, халыкара кинофестивальдә үзбәк, таҗик, казах, төрекмән һ.б. экраннан үз телләрендә сөйләгәндә, ислам кабул итү турындагы рус телле татар киносын карау күңелне тырнады. Төшерүчеләр моны «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең заказы буенча төшерүләре белән аңлатты. Киләчәктә «Хозур ТВ»-ның бу фильмын татарчага аудару, инглиз, гарәп телләренә тәрҗемә итү каралган.

Шри-Ланкада ниләр бар?

Фестиваль барыннан да бигрәк Казан һәм республикабыз халкына дөньядагы хәлләр турында мәгълүмат бирүе белән кадерле. Шри-Ланкадан «Газета» дип исемләнгән нәфис фильм дөньяга карашны киңәйтте. Сарат Коталавала һәм Кумара Тхиримадура фильмны үзләре төшергән, үзләре үк анда төп рольләрне башкара. Фестивальдә нәфис фильмда иң шәп ир-ат роле өчен бүләк шуларга эләкте. К.Тхиримадура 14 ел газетада хәбәрче булып эшләгән һәм редакция тормышын яхшы белә. Әмма фильм журналистлар турында түгел, ул хәерчелекне фаш итә. Бу фильмны төшерергә газетада басылып чыккан мохтаҗ гаиләнең тормышы турында бер мәкалә этәргән. Баш герой А.Шантаны сугыш вакытында машина шартлатуда гаеплиләр, бу хакта хәбәр газетада басылып чыга. Нахакка гаепләнгән ир-атны аякларын имгәткәнче кыйнап анасы, абыйсы белән авылдан куып чыгаралар. Инвалид арбасына утырган герой һәм аның якын дусты фильм буе башкаланың Коломбода шәһәрендә үз исемен аклап мәкалә бастыруларын сорап йөри. Баласының калада нинди мажараларга эләгәсен белсә, бичара ана гаделлек эзләргә дип чыгарып җибәрмәгән булыр иде, бәлки... Ниһаять, газета кулларында. Әмма тарихның ахыры шатлыклы түгел. Улы өчен ут йотып гомерен уздырган бичара ана инде гүр иясе. Кабергә капланган мәкаләне күргәнме, улын аклауларына сөенгәнме икән ул? Герой үзе исә анасының каберенә башын да сала алмыйча калды, бандитлар аны атып үтерде. Һәм газетада янә бер мәкалә басылып чыга. А.Шанта әфьюн бизнесы белән бәйле булып, үзләренекеләр тарафыннан атып үтерелгән, имеш. Язмыштан узмыш юк, диләр. Бәхетеңне тәкә сөзсә, көтү көтеп эшләгән акчаңны да ала алмассың, дип язган иде М.Мәһдиев. Кеше алдында йөзем ак булсын, дип ахыргача көрәшергәме?

(Дәвамы 5 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Туган телләр унъеллыгы

Россиядә 2022-2032 елларда «Төп халыклар телләренең халыкара унъеллыгы»н үткәрү турында быел 9 февральдә РФ хөкүмәте башлыгы М.Мишустин имзалаган карарга туры китереп, Татарстан хөкүмәте рәисе А.Песошин күптән түгел шундый ук исемдәге республика программасын имзалады һәм аны гамәлгә ашыру буенча оештыру комитеты да булдырылды. Анда бу чорда 68 чара үткәрү каралган. Алар арасында – фәнни-гамәли конференцияләр, әдәбият вә тел белеме, лингвокультурология, халык авыз иҗаты һ.б. өлкәләргә караган чаралар. Татарстан халыкларының телләре вә әдәбиятлары буенча фәнни-методик кулланма һәм ярдәмлекләр бастырып чыгару, диктант һәм олимпиадалар үткәрү, шулай ук туган тел укытучылары бәйгеләре оештыру кебек чаралар да каралган. Игътибарны укыту программаларына илдәге халыкларның традицияләрен һәм мәдәни хәзинәләрен өйрәнү буенча модульләр кертү, шулай ук тел сменалары булган күпмилләтле лагерьлар оештыру кебек чаралар да җәлеп итә. Татар телен саклау һәм үстерү буенча да җитди чаралар комплексы тәкъдим ителә. Алар арасында – яңа сүзлекләр вә сөйләшү кулланмалары, татарча топонимнар каталогы бастырып чыгару, яшьләр өчен «Татар гыйлеме» дигән халыкара фәнни мәктәп ачу һәм «Фәнни Татарстан» дигән журнал чыгара башлау, татар халкының рухи вә матди мирасын өйрәнү һәм тикшерү өчен Россия төбәкләренә экспедицияләр оештыру, татар теленә читтән торып өйрәтү буенча «Ана теле» проектын дәвам итү һ.б. Республика программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы затлар итеп вице-премьер В.Шәйхразиев һәм аның оештыру комитетындагы ярдәмчеләре – мәдәният министры И.Әюпова, мәгариф һәм фән министры И.Һадиуллин билгеләнгән.

Шунысын да искәртеп үтик, дөньяда төп халыклар телләренең унъеллыгын үткәрү идеясе 2019 елда БМО Генераль Ассамблеясе (ГА) башлангычы белән игълан ителгән иде. Әлбәттә, аның артында туган телләрнең авыр хәле белән бәйле реаль проблемалар торуы барлык халыкларга да яхшы аңлашыла. Әмма, БМО КШ карарларыннан аермалы буларак, ГА карарлары үтәү өчен мәҗбүри түгел. Шуңа да карамастан, Россия БМО әгъзаларыннан беренчеләрдән булып ГА башлангычын үтәргә алынды һәм моңа шатланырга гына кирәк кебек. Әмма 24 февральдән соң Россиянең халыкара оешмалар белән (шул исәптән ЮНЕСКО белән дә) мөнәсәбәтләре кискен үзгәрде һәм «Төп халыклар телләренең халыкара унъеллыгы»н үткәрү теләге дә ничектер сүлпәнәя төште. Шуңа да карамастан, Татарстан хөкүмәте азчылык халыкларның туган телләрен саклап калу буенча каралган чараларны ЮНЕСКО канаты астында үткәрергә карар кылды һәм мондый кыюлык һәр тарафтан хуплануга да лаек иде кебек. Әмма хәлләрнең реаль торышы республикада да оптимизмга әллә ни урын калдырмый. Чөнки дәүләт тарафыннан бүген үткәрелә торган гайре табигый милли сәясәт стратегиясе фонында төп халыкларның туган телләре белән бәйле проблемалар хакимияттәгеләр өчен формаль һәм кирәксез нәрсәгә әйләнеп бара.

Мондый мөнәсәбәт тулысы белән татар теленең бүгенге торышына да кагыла. Әйе, рәсми яктан ул Татарстанда дәүләт теле санала. Әмма аның рәсми статусы реаль законнар белән якланамы? Татар телен мәктәпләрдән куганда тырышкан хокук саклау органнары аның Төп Законда (турыдан-туры үтәлешле хокукый актта!) беркетелгән хокукый статусы үтәлешен ни өчен үз контроленә алмый? Моның өчен илдә нинди җаваплылык каралган? Татарстан президенты, Дәүләт Советы, ТР Конституция суды һәм, гомумән, гамәлдәге юриспруденция мондый хокукый вакханалиягә ни сәбәпле юл куя? Татар теленә бүгенге сансыз мөнәсәбәтнең тамырларын әнә шул сорауларга җаваплардан эзләргә кирәктер. Әлбәттә, Татарстанда кабул ителгән «Төп халыклар телләренең халыкара унъеллыгы» программасы үтәлергә тиеш. Әмма андый чаралар гына бүген татар теленең тулы хокуклы яшәешен тәэмин итә алмый. Татарстанда аңа ихтыяҗ тудыра торган һәм аның «дәүләт теле» статусын мәҗбүри итә торган (әйтик, Россиядә рус теле статусы үрнәгендә) яңа законнар кабул ителүе лязем. Юкса, элмә такталарда иң күп хата тапканнарга грант өләшү кебек хилаф ысуллар татар телен тискәре нәтиҗәләргә генә китерергә мөмкин. «Дәүләт теле» статусы ул аңа ия телнең дәүләт кайгыртуына алынуын аңлата.

Фоат УРАЗАЙ.

Театрлар дөньясында

К.Тинчурин театры Кәрим Тинчуринның тууына 135 еллык уңаеннан аның исемен йөрткән паркта әдәби-музыкаль флешмоб уздырды. Халык каршында театрның камера оркестры, артистлар Гөлчәчәк Хафизова, Резеда Төхфәтуллиналар чыгыш ясады. Айсылу Мөсәлләмова белән Булат Зиннәтуллин данлыклы «Сүнгән йолдызлар» спектакленнән өзек күрсәтте.

К.Тинчурин театры базасында яшь режиссерлар өчен бер еллык курслар ачыла. Дәресләрне Тинчурин театрының баш режиссеры Туфан Имаметдинов алып барачак.

Иртәгә тинчуринлылар Самара шәһәрендә «Хыялый» спектаклен күрсәтәчәк. Шулай ук сентябрь аенда Чуашиягә иҗади сәфәр планлаштырыла, октябрьдә театр Мәскәү, Ижау, Чаллы, Түбән Кама, Баулы, Азнакай шәһәрләренә гастрольгә чыгарга җыена.

Сезон ачылыр алдыннан камаллылар, традициягә тугры калып, Яңа-Татар бистәсе зиратына юл тотты. Монда алар бакыйлыкка күчкән театр әһелләренең каберләренә чәчәкләр куйды.

Минзәлә, Әтнә, Әлмәт театры бу көннәрдә Чечня Республикасы мәркәзе Грозныйда «Федерация» Бөтенроссия милли театрлар фестивалендә катнаша. Әлмәтлеләр «Җил артыннан», әтнәлеләр «Алмачуар», Минзәлә театры артистлары «Сөясеңме, сөймисеңме?» спектаклен тәкъдим итә.

Г.Кариев театры тамашачылар өчен театр буйлап экскурсия уздырды.

Буа театры 3 октябрьдә Санкт-Петербургның Яшь тамашачы театрында «Бәхеткә юл кайдан?» мелодрамасын күрсәтәчәк.

Уфада СССРның халык артисткасы, С.Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, профессор Гөлли Мөбарәковага истәлек тактасы ачылды.

«Апуш» театр студияләренә уздырылган кастинг нәтиҗәсендә Казан шәһәреннән, Балтач, Биектау, Арча, Саба районнарыннан Ленин исемендәге мәдәният йортына 33 укучы һәм «Чулпан» мәдәният үзәгенә 22 укучы сайлап алынды.

Иртыш буенда зур бәйрәм

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендә республика делегациясе Казахстанның Абай өлкәсе башкаласы Семей шәһәрендә булды. Анда беренче халыкара Иртыш буе Сабан туе узды. Татарстан делегациясе составында Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразиев, Дәүләт Советы депутатлары Рамил Төхфәтуллин, Альбина Насыйрова һәм башка рәсми затлар бар иде.

Ф. Мөхәммәтшин өлкә хакиме Нурлан Уранхаев белән очрашуда мәгърифәтче, казах әдәбиятына нигез салучы бөек Абайның ватанына килү мөмкинлеге өчен рәхмәт әйтте. Н.Уранхаев билгеләп үткәнчә, Семейдә узган беренче халыкара Иртыш буе Сабан туена Казахстан шәһәрләреннән һәм авылларыннан гына түгел, бәлки Иртыш ярларында урнашкан Омск, Тара, Тобол, Ханты-Мансийск шәһәрләреннән дә татарлар җыелган. «Безнең өлкә, бөтен Казахстан кебек үк, күп милләтле, – диде ул. – Бездә элек-электән шушы җирдә яшәгән татарлар белән тугандаш мөнәсәбәтләр урнашкан. Сабан туеның югары дәрәҗәдә оештырылуы безне шатландыра. Безнең тугандаш бәйләнешләр тагын да ныгыр дип өметләнәбез».

Аннары делегация әгъзалары 30 ел тарихка ия Татар сәнгать мәктәбендә булды. Мәктәпкә нигез салучыларның берсе – Габделәхәт Ахунҗанов, һәрьяклап ярдәм күрсәткәннәре өчен, Татарстан җитәкчелегенә рәхмәт белдерде, учреждение эше турында сөйләде, һәм кунакларны мәктәпнең иҗади талантлары белән таныштырды. Очрашу истәлегенә Ф.Мөхәммәтшин мәктәпкә тальян гармун бүләк итте.

Семей шәһәренең иң матур җирендә урнашкан Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасыннан соң Иртыш яр буенда (бу яр буе хәйрияче Рафаил Хаҗипов ярдәмендә төзекләндерелгән) Ф.Мөхәммәтшин һәм Н.Уранхаев иҗади интеллигенция һәм җәмәгатьчелек вәкилләре белән аралашты, Абай Кунанбаев һәйкәленә чәчәкләр салды.

Иртыш буе Сабан туенда Россия һәм Казахстанның төрле төбәкләреннән бәйрәмгә килгән кунакларны сәламләп, алар 2013 елда Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев катнашында салынган аллеяда агачлар утыртты.

Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында кунакларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән бәйрәм белән котлады һәм Сабан туе Иртыш ярында яшәүче төрле милләт кешеләрен тагын да якынайтачагына ышаныч белдерде.

Сабан туе Бәйбитшилик утравында узды, анда 10 меңгә якын кеше катнашты. Бәйрәм төрле милли уеннар белән үрелеп барды.

Барлык кунаклар өчен дә чын бүләк – Татарстанның Актаныш районы тәкъдим иткән авыл утары стилендә бизәлгән мәйданчык булды. Биредә кунаклар өчен тегермән, мунча, йорт торгызып куйганнар, кайнар чәй һәм традицион татар тәм-томнары белән сыйлана алсыннар өчен, Татарстаннан самавыр да алып килгәннәр. 1000 литрлы зур казанда татар һәм казахларның иң яраткан ризыгы – шурпа пешерелде.

I Иртыш буе халыкара Сабан туеның абсолют батыры булып Казахстан Республикасы көрәшчесе Эскархан Осканов калды. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров җиңүчегә Татарстан Президентыннан төп бүләк – квадроцикл тапшырды.

Төньяк башкалада

Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендә Татар мәдәнияте көннәре уза. Бу шәһәрдә әлеге чара 2015 елдан бирле үткәрелә. Быел ул Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу белән ачылды.

13 сентябрьдә Санкт-Петербург Рәссамнар берлеге залында Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Роберт Мифнең «Сайланмалар» дип аталган шәхси күргәзмәсе ачылды.

21 һәм 22 сентябрьдә Александр театрында «Ирдәүкә. Мөһаҗирләр» спектакле премьерасы була. Тамаша кичке сәгать җидедә башлана. Спектакль татар телендә рус теленә синхрон тәрҗемә белән барачак.

Санкт-Петербургның татар мәдәни үзәгендә рәссам Сания Бәхтияровага багышланган истәлекле чара узачак. Шулай ук Петербург Ислам мәдәнияте музее директоры, тарихчы Е.А. Резван белән очрашу булачак.

6 октябрьдә Татарстанның Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллегендә рәссам Елена Остраяның «Вслед за солнцем» дип аталган шәхси күргәзмәсе ачылачак.

1 нче биттә – Казан Халыкара мөселман киносы фестиваленең ябылу тантанасыннан бер күренеш. **Фото: mincult.tatarstan.ru**

Разил Вәлиев кичәсе көтә

Разил Вәлиев – Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, танылган прозаик, драматург, җитмештән артык китап авторы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Эшчәнлегенең кайсы өлкәсен алып карасак та, ул бер юнәлеш, бер агым буйлап кына бармый. Әле тирән фикерле, хисчән шигырьләре белән уйландыра, үзәкне өзәрлек җырлары белән моңландыра, әле халык, тарих, киләчәк, бүгенге вәзгыять турында кыю фикерләрен проза әсәрләренә сала, әле кызыклы, шул ук вакытта мәгънәле сәхнә әсәрләре белән тамашачыны җәлеп итә, әле балалар теле аша дөньяны танып белергә, укучысына да аңлатырга тырыша, әле туган телдә дөнья әдәбияты белән таныштыра, әле милләт тормышын, мәдәнияттә һәм мәгарифтә халкы мәнфәгатьләрен яклап сәясәткә кереп чума. Аның киңкырлы эшчәнлегенең һәр өлкәсенең үзәгендә халкы, туган иле өчен янып-көеп яшәүче шәхес тора.

Разил Вәлиев беренче чиратта шагыйрь булып танылды. Ул – хис белән фикердән тәкъя үрүче иҗатчы. Аның иҗатының бу үзенчәлеген үз вакытында академик Миркасыйм Госманов та ассызыклап үтә: «Чын шигъриятттә фикер белән хис, моң органик һәм табигый рәвештә бергә үрелеп, укмашып беткән булырга тиеш. Гел салкын акылга нигезләнгән фикер тиешле тәэсир тудырмаган төсле, фикерсез, мантыйксыз тойгыларга гына корылган «хисләр» дә тәэсирле була алмый. Разилнең шигырьләрендә, җырларында менә шул ике башлангычның икесе дә, органик һәм табигый бергәлектә килеп, аерылгысыз сыйфат хәлендә буйдан-буйга сузылып бара. Хәтта уй-фикергә әлләни урын бирелмәс кебек «саф лирик» әсәрләрендә дә, төптәнрәк уйлап карасаң, тирән иҗтимагый фикер гәүдәләнгән була».

Мәскәүдә СССР Язучылар берлегенең М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укучы яшь егетнең авылын, әнисен сагынып язган шигырьләреме ул, әллә соңрак тормыш юлы үткән, тәҗрибә тупланган аксакал шагыйрьнең туган нигез, атаана хакы турында уйланулары – аларның барысында да сагыну хисе белән бергәттән халкыбызның олы фаҗигасе, шанлы үткәне чагылыш таба. Мәсәлән, «Әнкәйгә хат», «Дисбе» кебек, иҗатының башлангыч чорында язылган шигырьләрендә үк Р.Вәлиев гап-гади сүзләр белән халкыбызның кантарлы үткәнен һәм бүгенгесен ачып сала, әлеге әсәрләрдә үк милләт язмышын кайгыртучы көрәшче чагылыш таба.

Р.Вәлиев шигърияттен нинди дер агым-юнәлешләр, формалар кысасында бәяләп булмый. Ул, шагыйрьнең үзе кебек, күптөрле, үзгәрүчән, һәрвакыт эзләнүдә. Биредә без төсләр гаммасы аша хис-кичерешне белдерүне дә, үткен фикер аша бүгенге вәзгыятькә тәнкыйди карашны да, бар дөньяга, гүзәллеккә, табигатькә, туган якка яисә бер чибәргә карата җавапсыз мәхәббәт утында янучы гашыйкны, Ватанын сөюче, аңа тугрылыклы хезмәт итүче улын да очратабыз. Р.Вәлиев шигърияте форма ягыннан да төрле. Ул әле фикерен классик шигъри юлларга сала, әле, барлык кысаларны алып ташлап, ак шигырьләр иҗат итә, әле үзеннән-үзе көй сорап торучы җыр юллары суза. Бу – шагыйрьнең яңалык уйлап чыгарырга омтылуы түгел, ә аның һәрвакыт эзләнүдә, тынгысызлыкта булган рухи халәтенең шигъриятендә чагылыш табуы.

Р.Вәлиев – бик күп җырлар авторы. Аның шигырьләренә язылган ике йөздән артык җыр бар. Татар җыр сәнгатендә җыр язучылар шактый. Бүген яңгыраган җырларның күбесе мәгънәсез сүзләрдән, бер-ике җөмләне кабатлаудан тора. Алар – бер көнлек, ничек яңгырасалар, шулай халык хәтереннән төшеп тә кала, югалалар. Бу – Р.Вәлиев сүзләренә иҗат ителгән җырларга кагылмый. Аның җырлары халыкчанлыгы белән, хис һәм фикернең бергә үрелеп баруы белән аерылып тора. Әдипнең әсәрләренең күбесе буыннанбуынга җырланып, халык аларны үзенеке дип кабул итте. Р.Вәлиев җырларында мәхәббәт, яшьлек дәрте дә, тарихи темалар да чагылыш таба. Аның иҗаты композиторларны мәгънәле, сурәтле булуы белән җәлеп итә. Шагыйрь «Нигә, әни, нигә картаясың?», «Сагынам» кебек җырлары белән әниләргә мәдхия укый. «Сагынам» җырына югары бәя биреп, язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев: «Бу җырны тыңлаганда тәэсирләнмәгән, газиз әнкәсенә булган ярату, сагыну хисләре ташып чыкмаган кеше юктыр дип уйлыйм мин», - ди. Язучы әниләр турында бик күп җырлар язылуын һәм онытылуын, ә бу әсәрнең буыннан-буынга күчеп баруын ассызыклый. Р.Вәлиевнең җырлары озын гомерле, алар халык күңеленә уелып кала. Шагыйрьнең «Бергә узыйк Казан урамын» җыры күп гаиләләрнең гимнына әверелгәндер, күпме гашыйк, «Зинһар өчен, кермә төшләремә», «Беренче мәхәббәт урамы», «Кышкы учак» җырларына кушылып, беренче мәхәббәтләрен исенә төшереп сагышлангандыр. Җыр сәнгатендә Р.Вәлиевнең бәһасез кыйммәте - аның балалар өчен язылган җырлары. Балаларның кызыклы дөньясын чагылдырган, аларны туган җирне, туган телне яратырга өйрәткән җырлары белем һәм тәрбия өлкәсендә зур хезмәт башкара. Бу җәһәттән, күпләрне белем дөньясына алып кергән «Әлифба» җырын атау гына да җитәдер. Разил Вәлиев җырларының көй авторлары арасында Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Резеда Әхиярова, Луиза Батыр-Болгари, Шамил Тимербулатов, Рәшит Кәлимуллин, Рәшит Абдуллин кебек мәшһүр композиторларыбыз булуы үзе үк аның шигырьләренең югары камиллектә иҗат ителүе хакында сөйли.

Гүзәл НАСИБУЛЛОВА,
филология фәннәре
кандидаты.

Быел Разил Вәлиевнең туунына 75 яшь тулды. Шул уңайдан 26 сентябрьдә, 19.00 сәгатьтә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында шагыйрьнең иҗат кичәсе үткәрелә. Кичәдә Венера Ганиева, Филүс Каһиров, Алинә Шәрипҗанова, Эльмира Кәлимуллина һ.б. популяр җырчылар, Камал театры артистлары, шагыйрьләр һәм күренекле сәнгать осталары катнаша.

Үзешчәннәргә иҗади мөмкинлек

«Тәртип» радиосы «Үз илемдә – үз көем» бәйгесен башлап җибәрә. Былтыр бәйгедә аерым башкаручылар һәм коллективлар катнашса, быел конкурста үзара гаиләләр көч сынашачак. Төп шарт – музыка уен коралларына кушылып җырлау яки җырны акапелла башкару.

«Узган ел бәйгегә йөздән артык видео килде. Әбиләр дә, бабайлар да катнашкан иде», – диде «Тәртип» радиосы баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлева.

Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге комиссия әгъзалары барлык видеоларны карап, берничә җиңүче гаиләне сайлаячак. Алар 29 ноябрь көнне Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә узачак Гала-концертта чыгыш ясаячак. Шулай ук җиңүчеләрнең җырлары «Тәртип» радиосы эфирында да яңгыраячак.

«Тәртип» радиосының башкарма продюсеры, алып баручы Айваз Садыйров әйтүенчә, бәйге халык, тыңлаучылар арасында профессиональ сәхнәгә чыгарга лаек булып та, ниндидер сәбәпләр аркасында мөмкинлегә булмаганнарны халыкка ишеттерү форсатын тудырды. «Хәтерләсәгез, Татарстан радиосы элек зур эш башкаран: үзешчәннәрне авыллардан, районнардан китереп, аларны фондка яздырганнар. Хәзер дә без фондны карыйбыз, өйрәнәбез – анда теге яки бу колхоз исеменнән килгән үзешчәннәр, җырчылар, ансамбльләр булган. Ул вакытта үзешчәнлеккә зур игътибар бирелгән. Бәлки, без дә шушы эшне әлеге конкурс аша дәвам итәбездер, чөнки монда катнашкан тыңлаучыларның язмаларын архивлаштырып, радио аша да яңгырата алачакбыз», – ди Айваз Садыйров.

Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов билгеләп үткәнчә, бәйгенең төп максаты – татар милли моңына, аһәңенә туры килгән җырларны сайлап алу. «Алар бүгенгә кадәр без ишетмәгән җырлар булырга мөмкин, чөнки халык арасында андый җырлар саклана. Милләтебезне уятып җибәрә торган җырларны табып, киң тамашачыга тәкъдим итә алырбыз дип өметләнәм. Без туганлык җепләренең ныклыгын, җыр, моң аша ныгытасыбыз килә», – диде ул.

Оештыручылар җиңүчеләрнең акчалата бүләкләнәчәген әйтте. Гран-прига – 50 мең сум, беренче урынга – 25 мең, икенче урынга – 15 мең, өченче урынга – 10 мең биреләчәк.

Бәйгенең төп шартлары: катнашучылар бер гаилә әгъзалары яки туганнар булырга тиеш (мәсәлән, әти-әни һәм балалар, ир һәм хатын, әби һәм оныклар, бертуган, туганнан туган һ.б.). Кимендә ике кеше булуы шарт. Катнашучылар сирәк яңгыраган яки онытылып барган җырны музыка уен коралларына кушылып җырларга яки җырны акапелла башкарырга тиеш. Җырны башкаруга иҗади килү хуплана.

Җырны видеога төшереп, сыйфатлы видеоны +79872205050 номеры буенча ватсапка яки телеграмга җибәрергә. Видеолар 16 октябрьгә кадәр кабул ителә.

Бәйге Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә оештырыла.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

● «Работа.ру» сервисы сораштыруыннан күренгәнчә, Татарстан башкаласы югары фәнни потенциалга ия. Шәһәрләр югары белем алу мөмкинлеге, фәнни потенциал, мәдәниятсәнгать оешмалары саны һәм тарихи мирас буенча бәяләнгән. Катнашучылар Казанда сыйфатлы югары белем алу мөмкинлеген һәм башкаланың бай тарихын билгеләп үткән. Рейтингта беренче урынга Санкт-Петербург, икенче урынга Мәскәү, аннары Новосибирск куелган, Казан – дүртенче. Лидерлар арасына шулай ук Калининград, Түбән Новгород, Владивосток, Ростов-на-Дону һәм Төмән дә кертелгән.

● «Промрейтинг» агентлыгы мәгълүматы буенча, Татарстан Республикасы ЮХИДИ камералары саны буенча Россиядә беренче урында бара – бездә юлларны 4723 камера күзәтә. Икенче урындагы Мәскәүдә 3969, өченче урындагы Свердловск өлкәсендә 2705 камера эшли.

Зур экранда – дөнья сулышы

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Әллә үзеңнең гаепсез булуыңны белеп, бернәрсәгә карамыйча, тыныч кына яши бирергәме? Улын гаделлек эзләргә чыгарып җибәрмәсә, бәлки, ананың ялгыз алачыкта үлеме шулкадәр аяныч булмас иде. Фильмда хәерчелек, адәм баласының хокуклары киселү үзәк өзгеч итеп сурәтләнгән. Бай булса, Шантаны бер редакциядән икенчесенә типкәләп йөртерләр идемени? Хәерчелек җинаятьне арттыра, дигән фикер кадр саен ярылып ята. Матбугат - җәмгыятьнең көзгесе, шулай булгач, «Газета» дип исемләнгән әлеге фильм җәмгыятьнең җитешсезлекләрен күрсәтә. Бернигә дә карамастан Шри-Ланкада кино зур урында тора. Кинофильмнарны төрле телләрдә һәм күпләп төшерәләр. Бу мәсьәләдә Шри-Ланканың Һиндстан белән якын булуы, атаклы Боливуд традицияләре хәлиткеч роль уйнагандыр, мөгаен. Эшмәкәрләр үз акчаларына төшергән фильмнар да күп. «Газета» да шундыйлардан. Продюсеры үз акчасына, «Газета»ны да санап, барлыгы биш фильм төшерүе турында әйтте. Фестивальдә Шри-Ланка фильмнары фанатлары да барлыкка килде, хәерчелекне фаш итсә дә, аларның сыйфаты гаҗәп дәрәҗәдә югары...

Филләрнең дусты кем?

Һиндстан халкы да җырлап-биеп кенә йөрми, җитди проблемалар чишә. Режиссер Крипал Калита төшергән «Хати Бонду» тулы метражлы документаль фильмында, мәсәлән, урманнарын кисү нәтиҗәсендә азыксыз калган филләрнең көтүләре белән авылларга килеп, ужымнарны юкка чыгаруы турында бәян ителә. Бер филгә көненә 500 килограммга кадәр азык кирәк. Ассам төбәгендә яшәүчеләрнең 70 проценты авыл хуҗалыгы продукциясе белән яши, көн күрә. Авыл кешеләре - филгә, фил авыл кешеләренә каршы чыга. Үлем очраклары да байтак. Бу көрәштә кайсы як җиңәр? Әлеге сорауга төгәл генә җавап бирү кыен. Әмма «Хати Бонду» командасы барлыкка килгәч, мәсьәлә бераз җиңеләя төшкән. Алар филләр өчен үлән, банан утырта, фил көтүләре йөргән юлларны өйрәнеп, карталар төзи, юлларында очраган куркыныч киртәләрне юкка чыгару, әйтик, электр чыбыкларын югарырак күтәрү белән мәшгуль. Хәтта авыл халкын филләр өчен махсус дөге утыртырга күндергән. Башта карышкан булса, авыл халкы филләрне саклау, цивилизациядән яклау кирәклеген аңлаган. Кемгәдер фил кадерле, ә кемдер һаман сукбай этләр проблемасын хәл итә алмый. Котырган этләр талап үтергән балаларны чебенгә дә күрми...

Лакит кем ул?

Режиссер, сценарист Мария Иванова Сурае «Мин лакит түгел» документаль фильмында Ливанда әлегә кадәр яшәп килгән атасыз балалар проблемасын бәян иткән. XXI гасырда да Ливан халкы 1925 елгы закон буенча яши. Бу канун нигезендә атасыз туган балалар бөтен хокуклардан мәхрүм ителә, аларга паспорт, гражданлык бирелми. Ливанда 18 төрле дини җәмгыять булса да, бичара балаларны берсенә дә якын җибәрмиләр, цифрлаштыру заманында алар укый-яза белми. Гадәттә зинадан туган балаларны, интекмәс өчен, аналары ташлап китә һәм алар бала йортларында яки урамда үз көннәрен үзләре күрергә мәҗбүр. Атасыз балаларны тамак хакына җаннарын алганчы эшләтәләр, кол итеп тоталар. Ливанда баланы асрамага һәм уллыкка алу катгый тыелган. Бичара сабыйларны чит ил кешеләре үзләренә алса гына. Әмма бу мәсьәлә дә бик четерекле икән. Хәлне уңай якка үзгәртү өчен, беренче эш итеп гражданлыгы булмаганнарны исәпкә аласы иде дә бит. Әмма Ливанда соңгы җанисәп 1932 елда үткән... Фильмның герое 23 яшьлек Салих бик күпне күргән. Бөтенләй сөйләшми диярлек. Алар җиде бертуган. Өчесен балалар йортларына, реабилитация үзәкләренә алып киткәннәр. Аналары сигезенче баласын дөньяга китерергә тора. Мария Иванова Сурае аны акча вәгъдә итеп кенә камера каршына китереп утырткан. Мария үзе Ливан кешесендә кияүдә. Ире өчен лакитлар мәсьәләсе гадәти хәл булса, М.Сурае бу хәлләргә бик өзгәләнгән, Салихның кол булып яшәвен күреп йөрәге түзмәгән, егетне урлап, Бейрутта картлар йортына урнаштырган. Кемдер филләрне коткара, кемгәдер кеше гомере дә берни түгел. Режиссер Ливанда гына түгел, Якын Көнчыгыш илләренең байтагында атасыз балалар проблемасының әлегәчә хәл ителмәгән булуын ачыклаган. Лакитлар бар да, юк та. Шунысы аяныч: күбесе җинаять юлына баса...

28 елдан соң көрәшү

Ираннан Мохсен Исламзадәнең «Сине беркем дә көтми» документаль фильмы тетрәндерде. 28 ел әүвәл ире җәберләвеннән качып ике баласын калдырып киткән һәм гомерен урлап, әфьюн кулланып үткәргән Мона исемле бер хатын-кызның тарихы бу. Моннан дүрт ел элек ул Тәһранда Ализадә белән таныша. Әфьюн кулланучы хатын-кызларга ярдәм белән шөгыльләнгән бу шәхеснең тернәкләндерү үзәгенә килеп, аның уң кулына әйләнә, начар гадәтен ташлый. Монаның бу дөньяда бер генә теләге бар – балаларын эзләп табу. Әмма күпме эзләсә дә, балаларының кайда булуын беркем белми. Үзәкнең җитәкчесе Ализадә бөтен таныш-белешләрен күтәреп, эзләп таба балаларны. Фестиваль кунаклары Монаның 28 елдан соң улы белән көрәшү мизгеленә шаһит булды. Авыр булды бу очрашу. Наздан мәхрүм иткән, ятимлек упкынына ташлаган ананы ничек гафу итәргә? Ир-бала нечкә күңелле булып чыкты. Кызы исә Монаны гафу итә алырмы? Аңа кызыннан бәхиллек алырга ашыгырга кирәк. Озакламый Мона инвалид калырга мөмкин. Сукбай тормыш нәтиҗәсе бу. Кызганыч ки, Мона кебекләр реабилитация үзәгендә егерме бишләп хатын-кыз...

Раззук гаиләсенең тату салоны

Израиль режиссеры Орит Офир Ронелл төшергән «Раззук гаиләсенең тату салоны» фильмындагы хәлләргә күңел ышанмый. Раззуклар гаиләсендә беркайчан да низаг чыгарга мөмкин түгел иде кебек. Ник дигәндә, аларның бабалары моннан 700 ел элек изге эшкә керешкән. Иерусалимга гыйбадәт кылырга килгән кешеләрнең кулына истәлек өчен рәсем ясап җибәрә торган булган. Баш герой Васил да, аның атасы, бабасы, туган-тумачасы да 700 елдан бирле килгән шул изге эшне дәвам итә. Бер көнне Васил рәсем калыпларының берничә төре җитмәвенә игътибар итә. Эзли торгач, нәселләрендәге ике туган арасындагы низагны ачыклый. Низаг нигезендә көнчелек, туганыңа караганда күбрәк акча эшләп баю теләге ята. Вакыйгалар туганнарның бер-берсен үтерүгә кадәр барып җитә. Раззукларны Ходай каргаган, ди халык. Изге гыйбадәт юлында килеп чыккан мондый түбәнлек адәм ышанмаслык хәл булса да, бу - чыпчын хәлләргә нигезләнеп төшерелгән документаль фильм. Изге дип саналган һөнәр Раззукларның бәхетеме, бәхетсезлегеме, дигән сорау туа.

Нәни Бахинең мажаралары

Дөнья гел караңгы төсләрдән тора, дигән фикер дөрес түгел. Бу җәһәттән Россиянең халык артисты Александр Галибин төшергән «Нәни Бахи мажаралары» фильмын искә алу да җитә. Танылган актер изге эшкә алынган – чит ил сериаллары карар көнгә калган балалар өчен нәфис фильмнар төшерә. Бу – Галибинның «Золотая рыбка», сугыш чоры турында башкортлар тормышыннан төшерелгән һәм күпләрнең мәхәббәтен яулаган «Сестренка», «Маруся фореva!», «Моя ужасная сестра» кебек эшләреннән соң гаилә белән рәхәтләнеп карый торган бишенче фильм. Вакыйгалар диңгез өсте тигезлегеннән ике мең метр биеклектә урнашкан бер Дагыстан авылында бара. Табигатьнең матурлыгына исләр китәрлек! Кинофильмда якты юмор, мажаралы хәлләр аша сигез яшьлек баланың җиңел генә өлкәннәр проблемаларын чишүе, тыңлаусызлыгы белән ата-анасы, әбисенең җан тынычлыгын алса да, чынлыкта, гаиләсенә чиксез сөенеч китерүе тасвирлана. Тормыш гади, өлкәннәр аны үзләре катлауландыра, дигән фикер кала. Бу фильм балаларның көзге каникуллары вакытында зур экранга чыгарга тиеш. А.Галибин яшүсмерләр өчен «Сыроежки» исемле нәфис фильмга тотынган. «Нәни Бахи мажаралары» фестивальдә иң шәп сценарий төрендә бүләккә ия булды.

Мас-рестлинг остасы Джулур

Бәйгедән тыш «Төрки дөнья» исеме астында күрсәтелсә дә, якут режиссеры Валентин Макаровның «Джулур: мас-рестлинг» фильмы мөселман фестиваленең рухына, калебенә туры килүе белән игътибарны җәлеп итте. Беренчедән, милли спорт төре мас-рестлингны зур экранга чыгарып, халыкара мәйданда танытырга теләүләре хөрмәт уята. Безнең дә милли көрәшебез, көрәшче нәселләр бар. Нигә алар турында нәфис яки документаль фильмнар төшермәскә? Джулур тарихының тагын бер уңышлы ягы – спорт турында булса да, миһербанлылыкны алга сөрүе. Джулур исемле егет авыр хәлдә калган гаиләсен коткару өчен зур ярышта җиңәргә тиеш һәм җиңә. Бар нәрсә көчкә, чибәрлек конкурсларына кайтып калган заманда бу фильм бигрәк тә әһәмиятле. Барысыннан да көчлерәк булу теләге сугышларга илткәне күз алдыбызда. Дөньяда миһербанлык булмаса, көчнең дә, матурлыкның да мәгънәсе югала.

Җиңүчеләр кем?

Ни аяныч, югарыда язып үтелгән фильмнарның берничәсе генә фестивальнең бүләкләренә лаек дип табылды. Иң яхшы милли фильм төрендә исә Әмир Галиәскәровның «Без – 41 нче ел балалары» бүләкләнде. Зөфәр Хәйруллинның сукыр бала язмышы турындагы киносы милли бәйгедә иң шәп документаль фильм дип табылды. Рифат Миндубаевның «Галиябану»ы Казан мэры призын алды. Казахстан белән бергә Г.Ибраһимовның «Алмачуар»ы буенча төшерелгән «Тарлан» тамашачы мәхәббәте бүләгенә ия булды. Жюри үз бүләген тоталитар тормыш шартларында язучының хәятен тасвирлаган «Мукагали» казах фильмына бирде. Лакитлар язмышына битараф кала алмаган Мария Иванова Сураеның ир белән хатын мөнәсәбәтләре аша төрле диннәр һәм мәдәниятләр конфликтын ачкан «Ачу» (Гнев) фильмы кино белгечләре гильдиясе бүләгенә ия булды һәм бер үк вакытта «иң шәп оператор эше» төрендә җиңде. Гран-при иясе – Иранның Нахид Хәсәнзадә төшергән «Тын дан» нәфис фильмы.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Күңел ярларында – яшь бөртеге...

"Синең җанга узсам..." (2022) шигырьләр китабына автор истәлеккә язган "Ләйлә! Яшәргә, язарга иде әле – укучысы гына бетеп бара. Авыр хисләр белән, Рифә", дигән юллар күңелне кинәт сискәндереп куйды... Кулга килеп кергән җыентык исә тормыш, иҗат, яшәеш турында төрле уйлар уятты.

Рифә Рахман иҗаты белән күптән таныш. Аның матбугатта даими басылып килгән шигырьләрен, проза әсәрләрен күп укырга туры килде. Алардагы авыр язмыш сынауларын матур үткән йә булмаса котелмәгән хәл-вакыйга белән очрашканнан аптырап калган, беришләре мәхәббәт утында янып-көйгән геройлары – гадәти, иялэнгән, тормыштан әдәбиятка күчкән кешеләр, хисләре таныш, табигый кебек иде. Әммә, аның 2002 елда "Керфекле тәрәзәләр" китабы чыккач, бу шагыйрәнең үзенчәлекле, нечкә хисле, көтелмәгән "давыл-бураннар" кузгатырга сәләтле булуын аңладым.

"Керфекле тәрәзәләр" исеме үк әллә нинди уйларга этәрә. Без кемнедер өзелеп көткәндә тәрәзәләргә карыйбыз, уйланганда, шатланганда – тәрәзәдән киң дөньяга багабыз. Күз алдымда кешене әлеге дөнья белән тоташтырган гаять зур тәрәзә һәм анда урын алган озын керфекләр – лирик мин образы туды. Мәгънәле, көтелмәгән образ иде ул! Үзем дә "тәрәзәле" китап аша шагыйрә күңеленә, аның шигъриятенә узгандай булдым.

Бүген исә кулымда Рифә Рахманның юбилей уңаеннан Татарстан китап нәшрияты бастырган "Синең җанга узсам..." – моңарчы дөнья күргән кырык биш китап-рисаләләреннән берсе. Соңгысы булмастыр...

Җыентыкка кузәтүдә әйтелгән, "Лирик герой бай тормыш тәҗрибәсе туплаган, язмышында хәсрәтләр дә, шатлык-куанычлар да мул булган, яшәүнең кадерен һәм тәмен аңлаган хатын-кыз сурәтендә күз алдына килә", фикеренә мин "чын, садә дуслыкка сусаган" дигәнне дә өстәр идем, чөнки шигырьләрнең берсеннән икенчесенә күчә барган бу хис игътибарны аеруча җәлеп итә. Китап нәкъ менә "Дустың булыйм" дүртьюллыгы – табигатькә, сафлыкка мөрәҗәгать белән ачыла да:

Иптәшләрен уяткан да иртә таңнан,
Биек үлән арасында уйный бөҗәк.
Менсен учка – кулны куйдым.
Шундый чагым:
Минем җанны аңлый алыр бер дус кирәк.

Автор укучысы өчен йөрәгенә юлны – табигать җаны белән рифмалаштырып сала. Мондый – табигатьтән алынган образларга мөрәҗәгать иткән әсәрләр укучыларда күп вакыт гаҗәпләнү тудырмый, әмма Рифә шигырьләре түгел, чөнки ул аларга бөтенләй башка мәгънә сала. Кемдер табигать турында дип уйларга мөмкин булган "Яфрак буйлап..." әсәре – асылда иҗтимагый-сәяси лирика үрнәге. Шагыйрь анда тереклектәге җан иясе аша кешенең, милләтенең бәхеткә, ирекккә, мөстәкыйльлеккә омтылышларын, туган җиренә олы мәхәббәтен ача:

Бу дөньяны шундый-шундый ярата ул!
Үз туфрагы, үз куышы – аңа гына!

Шагыйрь карашынча, милләтенең бер баласы булган кеше туган көненнән каршылыклар эчендә торып кала. Әле беркемгә берниндизыян салмаса да, килачәктә аның, бөҗәк кебек үк, яшәү, исән калу өчен көрәшәсе ачык. Әлеге образ бер үк вакытта төрле сәяси шартларга куелган, заман зилзиләләренә каршы торган татар халкын да күз алдына китерә. Автор әкренләп дөнья һәм бигрәк тә халкы алдындагы шагыйрь миссиясе проблемасына килеп чыга:

Бөҗәктән дә кечкенәмен бу Галәмдә.
Зур булсын дип телим эшем
халкым өчен.
Көрәшәмен шигырь белән туган көннән
Бөҗәкнеке кадәр дә юк хакы өчен.

Тыныч тонда табигатьнең кечкенә генә, әмма лирик геройның күңелен җәлеп иткән бер күренешен теркәп башланган шигырь, фикергә киңәя барып, бөҗәк образының мәгънәви йөген тирән милли идеяләргә алып чыга. Җан иясенең ирекккә, бәхеткә омтылышы әсәр ахырында шуларга сусау тойгысына әверелә. Гомумән, Р.Рахманның киңкырлы иҗатында кешене, гаиләне, милләтне, әдәбиятны, шуның тәҗы булган шигърияте саклау идеясе, бигрәк тә иҗатчы хатын-кызның иҗтимагый вазифалары турында уйланулар күзгә ташланыр дәрәҗәдә калку ("Без – хатын-кыз", "Яңгыр көткәндә"). "Халык гамен җырлау – аның язмышыдыр", – дип әледән-әле искәртә шагыйрәнең кыю, көрәшче рухлы булып яратылган лирик герое.

Р.Рахманның табигатьтәге хәлләрне, эчке халәтне тасвирлаудан башланган күп кенә шигырьләре, укучыны, үзе турында да уйлата-елата, моңландыра-сагышландыра торгач, милләтнең бүгенге торышы турындагы уйлануларга алып чыга. Әйтик, "Ачыгыз тәрәзәләрне!" әсәре кешенең физик һәм рухи зәгыйфьлеген, аның кайбер сәбәпләрен сурәтләүдән башлана, әмма шагыйрьне бигрәк тә татар халкының хасталыгы – хәрәкәтсезлеге борчый:

Ачыгыз тәрәз милләткә,
Алсын өчен киң сулыш!
Саф һава кирәк аңа да!
Бик туйдырды бу торыш!

Укучыны кеше күңеленә якын, чишелеше аңлаешлы проблемалардан иҗтимагый-сәяси катлаулылыкларына тартып китерү – Рифәнең шулай ук күзгә ташланырлык әдәби алымнарыннан.

Шагыйрьләрнең гасырлар дәвамында кош-кортлар, табигать образларына аерым игътибары чынбарлыкны тулырак күзаллатырга ярдәм итә. Тотрыклы архетипны гәүдәләндергән һәм еш кына символлаштырылган табигать образларын шартлы рәвештә ике төркемгә бүләргә мөмкин. Алар арасында кешегә файдалылары яки зарар салмаучылары да (илаһи – умарта корты, ар хатыны h.б.), кешене уйсыз иткәннәре дә (түбән – чебен-черки, саранча h.б.) бар. Әлеге образлар безгә шигъриятне кабул итүнең яңарак формасын ача. Бу уңайдан, Р.Рахманның соңгы җыентыгына тупланган шигырьләрдә бөҗәк образының аеруча кызыклы икәнлеген ассызыклыйсы килә ("Эч бушатам", "Яфрак буйлап яңа туган бөҗәк бара", "Дустың булыйм"). Ул шагыйрә өчен дус:

Өстәл буйлап бөҗәк үтеп бара:
Белмим затын, белмим исемен.
Кайнатманы ашап уз инде, дим,
Кунак сөя торган кеше мин.

Рифә шигырьдә үз халәтен аңлатуга зур төгәллек белән якын килә. Ул урын-вакыт бирелеше белән тәгаенләштерелә:

Бул син миңа яңа танышым бер,
Чәй эчәргә иртән килачәк...

Строфаларда – вакыйгалар агымы. Беренче юлларда – реаль халәт:

Хәсрәтләрем күптер, чирләгән күп,
Дусларым аз: китеп бардылар...

Биредә XX1 гасыр чире – күпләрне гүр иясе иткән коронавирус хакында уйлар агышы. Соңгы строфалар исә яңа поэтика белән тулыландырыла, мәгънәсе киңәйтелгән метафорага әйләнә:

Сөйләр кеше юк бу сүзләрне,
Эч бушатам бөҗәк алдында...

Хис-фикер кечкенә проблемадан зурракка үсә бара:

Их, бөҗәгем, эшләр болай барса,
Минем халкым нишләр күрәчәк?

Шигырьдә мотивның көчле булуы да очраклы түгел. Төп хис-фикер – үлем-яшәү мәсьәләсе белән бәйләнгән. Алдарак мисал итеп китерелгән "Яфрак буйлап яңа туган бөҗәк бара" шигырендә дә бөҗәк образы геройның эчке дөньясын һәм яшәешкә мөнәсәбәтле уйларын, газапларын ачарга, зуррак фикер әйтергә ярдәм иткән иде бит.

Геройның эчке сөйләмен поэтик гәүдәләндерү өчен табылган бөҗәкнең көтелмәгән образы хисне, барлык-юклык, яшәү-үлем фәлсәфәсен тулырак җиткерергә ярдәм итә. Нәтиҗәдә, капма-каршылык барлыкка килә. Ә бит ул – психологик анализының бер үзенчәлеге. Бөҗәк образы – тизләтелгән үсеш өчен этәргеч. Шуңа күрә геройның уй-тойгылары көчле һәм киеренке.

Шагыйрә җаны үзгәрешләр, "шифалы яңгыр" көтә. Ул шәхси тормышта да, халыклар, милләт яшәешендә дә булырга хаклы үзгәрешләр. "Дәвамчы бул", "Үзгәрешкә чакыру", "Яңгыр көткәндә", "Кыланыш", "Читтәге милләттәшкә" h.б. – шундыйлардан. Мондый лирик әсәрләрендә шагыйрә шартлылыклардан көчлерәк, ул – өметләнергә көч таба:

Зур көрәшләр генә алып килер
Ирек туен, көчле Ил туен.
Чигенелде... Ә син шул урыннан
Бер ыргылып кара, яшь буын!

Халыкта мәхәббәт шагыйрәсе буларак танылуына карамастан, Рифә Рахманның калку тудырылган үзәк герое – көрәшче, анда батырлар каны ага, бер шигырьдән икенчесенә күчә-күчә, ул чынбарлыкның гаделсез яклары белән дә, тел, милләт өчен дә көрәшүче.

Бу Галәмдә бар да үзгәрештә,
Хәтта мәңгелек дип тоелган.
Үзгәрешләр котәм! Беләм дә бит,
Алар канун белән тыелган...

Чынбарлык геройдан көчлерәк шул, ахыр чиктә өметсезлек, ачыргалану хисләренә дә урын бирелә:

Бөтен серен ирен читләрендә,
Сөйләп бирсәң, кем соң аңласын?
Бу Рәсәйдә хәтта татары да
Тылмач аша аңлый баласын.

Юк, шагыйрә әле тулаем өметсезлектә, яшәргә көч биргән музыкаль авазларны ишетүдән мәхрүм түгел. Ул көч – мәхәббәт. Лирик геройның төрле төсләргә бай ярату тойгылары баласына, оныкларына, әтиәнисенә, туган ягына, дусларына, сөйгәненә юнәлтелгән. Ул алар өчен борчылып, сөенеп, күңеленнән рәхмәт хисләре әйтеп, якыннарына хәер-теләктә булып яши. Шәһәрдә гомер итүенә карамастан, бу геройның авыл, авылның хезмәттәге көннәре, кешеләре белән бәйләнеше зур. Үз ягының табигате шагыйрәне хисләргә баета, каләменә иҗат рухы бирә. Ул тудырган герой исә – туган җиренә, һәр җан иясенә хәер-догада...

Рифә шигъриятe дә һәркемгә төрле ягы белән ачыладыр. Кемдер анда кайбер образларының моңа кадәр беркемдә күренмәгән мәгънәләренә таң калачак, кемдер иҗатының банальлектән бөтенләй азат икәнлегенә сөенер, кайберәүләр метафорлар ярдәмендә җиткерелгән фикернең дә табигый яңгырашына сокланыр. Шунысы бәхәссез: беркем дә шагыйрә язганнарга битараф калмас.

Ә бит әле Рифә Рахман шигырьләре, аталган сыйфатлардан тыш, гаҗәеп дәрәҗәдәге музыкальлек, лиризм белән дә аерылып тора. Шагыйрәнең бер үк вакытта галимәлеген дә сизми мөмкин түгел: аның әдәби алымнар арсеналы бик киң, ул алардан гаҗәеп оста да, урынлы да файдалана. Әйтик, Рифә иҗат иткән строфаларда фикер, сүзләр бик еш кабатланып килә. Бу төр композицион алым – лексик кабатлаулар кичерешләрнең зурлыгын ача, укучыга эмоциональ йогынты ясый, сөйләмгә махсус экспрессивлык бирә. Риторик мөрәҗәгать лирик хисләрнең чагылышын көчәйтә, уйланылган интонация исә шигъри сөйләмне нечкәртә: "Җылы өйдә әле нидән туңам?", "Нинди микән анда "көнторыш" h.б. Кагыйдә буларак, шигырьләрдә образның мондый психологик халәте еш кабатлана. Бу – геройның "авыру" халәте. Ул мәхәббәт белән авырый.

Шагыйрәнең мәхәббәт сүзләре – җылылык һәм рухи яктылык белән тулы хисләр дөньясы. "Синең җанга узсам..." шигырьләр җыентыгында Рифә Рахман көчле, якты һәм гаҗәеп үзенчәлекле шәхес булган лирик геройне ача. Ул якын кешеләренең бәхете өчен фидакарьлеккә әзер, үзенә һәм хисләренә тугъры, түземү, матурлык, сабырлыкка сусау кебек сыйфатлар белән характерлана. Шагыйрәнең иҗат дөньясы турында, аның үзеннән дә остарак итеп әйтеп булмас кебек:

Онытa алмыйм сөйгән ярымны да,
Онытырлык итте мең сәбәп.
Кемдер өчен ашау-эчү рәхәт,
Миңа шигырь язу – бер гадәт.

Әлеге гадәтеңне ташлама, Рифә! Яз, укучыларыңны әле озак еллар дәвамында шатландыр, дибез.

Ләйлә МИНҺАҖЕВА,
филология фәннәре докторы.

ТАУЛАР ИТӘГЕНӘ КӨЗ КУНГАН...

Таулар итәгенә көз кунган,
Ерганакта әле җәй калган.
Күңел күзе күргән кешегә
Җәйне искә алыр җай калган.

Таулар итәгенә көз килгән,
Каравылга чыккан йөз тилгән.
Йөз тилгәнгә тимәс берни дә:
Бәбкәләр каз булып өлгергән.

Бәбкәләр каз булып симергән...
Таулар итәгенә көз килгән.
Килер кышка юлны сызгандай,
Бер оя каз бара бер эздән.

* * *

Җәйнең матурлыгы чәчәкләрдә әле,
Кояш кайнарлыгы очкынлана күздә.
Яфрак арасына качып тора салкын,
Көз килгәнен кайчан чыгып әйтер безгә?

* * *

Биегәннәр иде уйнак кузлар
Күзләреңдә синең бервакыт...
Иң кайнары йөрәгемә төште,
Йокыдагы хисне уятып.

Четердәде тәнең учак кебек.
Учак тыны иде синең тын.
Дөрләдек тә кинәт сүрелдек без.
Ялкыннарны басты төнге дым.

Сүрелде хис, калды истәлекләр –
Җылы биреп тора йөрәккә.
Учакларның җаны – сөю иде!
Терелт әле кабат, кирәксә!

КЫЛАНЫШ

Чыгып йөргән булам урамнарга,
Киткән булам Кабан буена.
Яшел ярда яшь егетләр күрсәм,
Син киләсең тагын уема.

Син киләсең минем артларымнан,
Туктап көтеп торам, борылмыйм.

Рифә РАХМАН

Ә үбешсәк... Нидер яралырмы,
Берни булмагандай калырмы?
Каптыр алма (!) – дәрттән дерелдәгән
Ирен белән орлык алырмын.

СИН БАРСЫҢ

Син барсың йөрәктә,
Иртә-кич кагасың,
Эшләрдә онтылгач
Туктап та аласың.

Син барсың йөрәктә,
Шуңа да авырдыр.
Китсәң дә син аннан,
Җәрәхәт калырдыр.

Китмә син, яшә гел,
Көндезен тилмертми,
Югыйсә көн үтми,
Һичничек эш бетми.

Кичләрен йокларга
Яткач ук бир хәбәр.

Үлән арасына качып тора салкын. Яшен уйнаганда, көз тавышы килә...

Бәллүр чыңы тора дымлы һаваларда –
Менә-менә яңгыр явып узар җиргә.
Ныграк тибә дулкын елга ярларына,
Җәйне куган кебек килә, китә, килә...

Аның матурлыгы чәчәкләрдә әле,
Аның кайнарлыгы кипкән иреннәрдә.
Үлән арасына качып тора салкын.
Яшен уйнаганда, көз тавышы килә.

ТЕЛГӘ КИЛГӘН ГАРМУН

Ансыз да авыр күңелгә:
Сагыш көен тезә генә.
Телләрендә кеше моңы –
Җырлый гармун, үзә генә.

Уйналасы килә, ди ул,
Күреккә ут кабынганчы,
Яшәргә тиеш җырларым,
Ахыр сулышны алганчы.

Соң тапкыр тартылган күрек,
Күкрәк сыман ярылганчы –
Биетермен телләремне,
Сезне телсез калдырганчы.

Бар яше, шомарган, оста –
Көй эзләп һич юк торасы.
Гармунда сагыш тум-тулы:
Чыгармаса – буыласы.

Уйнатучы булмаса да,
Ул бүген түгелә генә...
Мин элек җырладым, ди ул,
Хуҗамның көенә генә.

Мин элек ачтым бик теләп
Аның сагышын-серләрен...
Җил табып баскан шикелле
Йөгерә гармун телләре.

Йөгерә... сөйгән хуҗасы
Туктаган бүген уйнаудан...
Гармунның җаны кыйналган,
Ташлады, диеп уйлаудан.

Карлыгыр чиста тавышы,
Бу кадәр ярсып уйнаса.
Ул гармун булыр идеме,
Елатмый хушлаша алса?

Шул хыялга һаман кайтаралгач,
Бик үз иттем Кабан буен мин.

Яшь егетләр кызлар сөйгән җирне
«Яшьлек яры» диеп атадым.
Бу ярларда бик аз яшәдек без...
Китмәсәк тә аннан картаеп.

Эзләп төшәм таныш сукмаклардан
Шул яшьлектән калган эзләрне.
Яшь егетләр сине хәтерләтә,
Беткәнсеңдер юкса үзгәреп.

ЮРАУЧЫ ЮРАП КИТЕРӘ

Бер әкият мине әсир итте,
Ахырында тәмам чирләтте.
Нигә әле, матур чишелеш көтеп,
Азаккача аны сөйләттем?

Бер патшаның, имеш, чибәр кызы
Бар егетне гашыйк иттергән,
Әтисенең кадерлесе булган,
Теләп табылган кыз, көтелгән.

Күрәзәче беркөн хөкемдарның
Йөрәгенә курку йөгерткән:
Кызны елан үтерәчәк дигән
Шомлы фараз аңа белгерткән.

Йолдызчының явыз юравына
Ата кеше ихлас ышанган.
Искитмәле сарай салдырган ул,
Биек койма белән кыршаулап.

Һәм боерган кызга берьялгызы
Шул сарайда гомер итәргә.
Булдыралмас, дигән тынычланып,
Ишегеннән үлем үтәргә.

Рәшәткәле булган тәрәзләре.
Бикләре нык булган ишекне
Ачып, эчкә уза алган бары
Тикшерүләр үткән пешекче.

Кыз саргайган, шыткан туфрагыннан
Өзелгәнгә шиңгән гөл кебек.
Ә бервакыт... төнлә елаган ул,
Төшендә бер гүзәл яр күреп.

Коткар мине, дигән, һичьюгында
Үлем элмәгенә тап юлны, –

Ул артыктыр яшәвемнән минем
Тар зинданның булып тоткыны.

Яши алмыйм сине күрмичә мин,
Рухым сынган тәмам, кителгән.
...Ашчы киемендә узган егет
Кәрзинендә елан (!) китергән.

СӨЙЛӘШҮГӘ СУСАУ

Сөйләр сүзләр мәңге бетми икән,
Истәлектән хисләр кабынгач та.
Дертләп китәм, синең дымлы тының
Колак очларына кагылгач та.

Син читкә куй мине назлавыңны,
Сөйләшик гел, бары сөйләшик гел.
Мәхәббәтнең була мең төрлесе,
Тәнгә тими сөю кадерледер.

Күздән узган хисләр хислерәктер,
Минем сөю шуның ишерәктер.
Шундый сөю уятырлык сүзне
Тыңлый-тыңлый искә төшерә тор.

БӨРЕЛЕ БОТАК ИДЕМ

Сөймәдем кулым талганчы,
Син һаман уртак идең...
Яшисе килгән бөреле,
Тамырлы ботак идем.

Корыды тамырларым да,
Коелды бөрем – кипте.
Танышкан көннән гомерем
Узды тик килде-китте.

Килде-китте яшәдең дә,
Үзгәрде сиңа хисем.
Сусын басарлык суың юк!
Син корый күрмә, дисең.

Тынны алырлык һава юк
Сулыйсы күзәнәккә.
Бөреле ботак идем мин
Сине тапкан сәгатьтә.

* * *

Ирен белән алма ярырмын мин,
Синең иренеңә кагылмам!
Шундый сүзләр бирәм үз-үземә
Үтеп киткәнеңдә янымнан.

Сүз белән кыйнарсың
Теләсәң никадәр.

Сүз белән уйнарсың,
Сүз белән сыйларсың.
Яратмыйм, дип әйтеп,
Мине дә сынарсың.

Син барсың йөрәктә,
Шуңа да авырдыр.
Тук та тук шакыйсың,
Җәрәхәт калырдыр.
Сиңа да мине бер
Җәлләргә ярыйдыр.

* * *

Син шәмәхә көзем микән минем,
Син миләүшә күзле яз микән?
Нигә һаман сиңа үпкәлим мин,
Биргән назың бик тә аз микән?

Үпкәләтер эшләр эшләдеңме,
Әллә берни эшләмәдеңме?
Яннарыма иртәләрен килдең,
Юри миндә кичләмәвеңме?

Назлар бирмәс өчен, матур сүзләр
Әйтмәс өчен, миңа эңгердә
Килмисеңме? Иләс-миләс хисләр
Үтәр дисең мәллә күңелгә?

Зәңгәр чәчәк аткан җәй түгел син,
Сары чәчәк аткан яз түгел.
Син – шәмәхә көзем минем. Йә хуш,
Минем яшьтә ул да аз түгел.

РЕДАКЦИЯДӘН. **Танылган шагыйрә, прозаик, галимә, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди, Ф.Хөсни, С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләр иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рифә Рахманга 18 сентябрьдә 60 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.**

Лаеш - башкалабызга терәлеп торган район. Үзенең мәйданы буенча җөмһүриятебездә бишенче урынны били, Чулман һәм Идел елгалары кушылган урында урнашкан. Халкына килсәк, районда яшәүче 62 мең кешенең 55 процентын урыслар, 42 процентын татарлар, 3 процентка якынын башка милләтләр тәшкил итә. Лаеш районы шунысы белән дә үзенчәлекле: аның барлык мәйданының 30 процентын су биләп тора. Шуңа күрә дә район халкы игенчелек һәм терлек асраудан кала, балыкчылык белән дә шөгыльләнә. Соңгы берничә елда районда эчке туризм да шактый нык үскән: «Чулман диңгезе»нә җәен бөтен Россиядән ял итәргә киләләр. Без район белән танышып йөргән көнне дә пляж зонасы янындагы парковкада Чечня, Дагыстан, Балкария, Чуашия номерлары белән килгән машиналар күзгә чалынды. Кунакларны иксез-чиксез җәйрәп яткан Чулман, аның заманча, матур итеп ясалган ярлары, мондагы төзеклек, уңайлыклар үзенә тарта, күрәсең. Лаеш шәһәренең тарихы бөек Болгар дәүләтенә барып тоташа. 1557 елдан монда урыс халкы китереп урнаштырыла башлый.

ЛАЕШ – КАЗАН КАПКАСЫ

ТАЛ ЧЫБЫГЫ ГЫНА ДИМӘ...

Лаешның үзендә әллә кайлардан килгән туристларның да күзен кыздырырлык матур әйберләр ясаучы алтын куллы оста яши. Нәрсәдән дисезме? Су буенда үсүче гап-гади тал агачыннан. Игорь Бурмистров – белеме буенча юрист, тал чыбыгыннан сәнгати эшләнмәләр ясаучы оста. Аның кул җылысын сеңдергән җиһазлар: тибрәнмәле кәнәфиләр, абажур, ваза, интерьер кирәк-яраклары бүген башкалабызның затлы рестораннарын бизи. Үзе ул бу һөнәргә китаплардан өйрәнгән, остаргач, үзе дә дистәләрчә кешене бу һөнәргә өйрәткән. Бу эштә иң авыры – чимал әзерләү, дип саный ул. Элек тал чыбыгын елга буеннан җыйган, хәзер исә аңа урман хуҗалыгы гектар ярым плантация утыртып биргән, анда ун төрле сорттагы таллар үсә. Хәзер чын талдан үрүче осталар бармак белән генә санарлык калган заманда, мондагы хакимиятнең халык һөнәрчелегенә шулай хөрмәт белән, кирәксенеп караву күңелгә ятарлык күренеш. Игорь да хезмәтен бәяләүләре өчен бик рәхмәтле. Аның хыялы да бар: үз һөнәренә яшь буынны өйрәтү өчен, һөнәрчелек палатасы канаты астында эшли торган мәктәп ачу. Чынга аша торган хыял булсын.

БАЙ ТАРИХЛЫ ИМӘНКИСКӘ

Имәнкискә – Казан ягыннан килгәндә олы юл өстендәге иң беренче татар авылы. Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алгач, шәһәргә 60 чакрым радиуста бер татар авылын да калдыртмаган. Ә Имәнкискә 59 нчы чакрымда урнашса да, исән-имин торып калган, чукындыручылардан да зыян күрмәгән. Моның тарихын болай аңлаталар: авылда, имеш, борынгы заманнардан ук каяндыр килеп утырган ике урыс гаиләсе яшәгән. Аларның йортлары авылга кергәч тә, суның бирге ягында урнашкан, ә татарларның йортлары суның икенче ягында. Урыслар татар күршеләр белән тату яшәгән, балалары бергә уйнап үскән, авыл аксакаллары аларга зыян салмаска кушкан, безгә алардан зур файда булыр, дигәннәр. Көчләп чукындырулар башлангач, чыннан да, бу сүзләр дөрес булып чыга. Чукындыручылар килеп төшүгә, авылның беренче йортына керәләр, аларны анда ипи-тоз, иконалар тотып каршы алалар да, авылда урыслар яши, дип озатып калалар. Шулай итеп, авыл чукындыру афәтеннән сакланып кала... Ә авылда урыслар яшәгән йортлар саны гомергә ике-өчтән артмаган...

Бу борынгы татар авылы Казан ханлыгы чорында нигезләнгән. И.Болтинның Писцовый кенәгәсендә исә Имәнкискә авылы 1603 елда телгә алына. Авыл табигатьнең бик матур җирендә, Чулманның киң булып җәелеп аккан урынына урнашкан. Җәйләрен монда дача алып ял итәргә килүчеләр дә күп. Имәнкискә Оренбург тракты өстендә утыра. Шуңа да авыл халкы сәүдәгәрлеккә хирыс: юл буенда каклаган каз, алма, җиләк, ысланган балык, казы кебек ризык сәүдәсе җәен дә, кышын да туктап тормый. Үзләрендә җитештерелгәнне дә, алып кайтып та саталар.

● Имәнкискә авылы мәчете.

Имәнкискә аша узган саен күз явын алырлык тимер капка игътибарны җәлеп итә иде. Бу юлы аны ясучы тимер остасы Раиф Габдуллинның үзе белән дә танышу насыйп булды. Ул ясаган нәкышлы капкалар бүген республикабызның барлык почмакларында да бар икән, оста аларның төгәл санын үзе дә белми. Раиф заманында мәктәптә физкультура укыткан, ун еллап элек тимер эше белән мавыгып киткән. Үзенә матур итеп койма ясап куя ул, шуны күреп, башкалар да заказ бирә башлый. Катлаулы бизәкле капка бер ай буе да эшләнә. Эшемне яратам, ди Раиф Рамазан улы. Аның Имәнкискәдә һәм Среднее Девятово авылларында урнашкан ике остаханәсендә хәзер 6 кеше эшли.

Бу авыл халкы динилеге белән дә аерылып тора. Имәнкискәдә мәчет 1992 елда ачыла, шуннан бирле аннан халык өзелми. Августның кызу көне булуга карамастан, без кергәндә нурлы йөзле бер абыстай ике-өч авыл баласына сүрәләр кабатлата иде. Таныштык, Миңлесорур апа Вагыйзь

● Имәнкискәдәге затлы капка.

● Капка ясау остасы Раиф Рамазан улы.

Мөсафир сәфәрдән кайтты

● Имәнкискә мәчетендә сабак алучы балалар һәм Миңлесорур абыстай.

кызы балаларны Казанда үтәсе Коръән укучылар конкурсына әзерли икән. Гомере буе мәктәптә тарих, җәмгыять белеме укыткан. «Бервакытта да балаларга кеше маймылдан барлыкка килгән, дип сөйләмәдем. Галимнәрнең бу мәсьәләдә 4 фикере бар, дип шуларны аңлатып китә идем», – дип искә ала абыстай. Бабасы да имам булган, намаз сүрәләрен кечкенәдән ятлап күңеленә сеңдергән. Юллар ачылгач, «Мөхәммәдия»гә укырга кереп, кичке бүлеген тәмамлый. Дүрт ел буе, бер дәрес калдырмыйча, һәр шимбә-якшәмбене Казанга йөреп укый. «Оялмыйча ничек дәрес калдырасың, мәдрәсәнең директоры Зөлфәт хәзрәт – минем укучым бит», – ди Миңлесорур апа. Заманында бу ханым мәктәптә искиткеч бай туган якны өйрәнү музеен төзегән, әле дә эшләп тора. Ул үзенең Имәнкискәдә археологик казу эшләрен алып барган Петр Старостинның укучысы икәнен горурланып искә алды. Музейга Имәнкискәдә казу эшләре барышында табылган барлык экспонатлар куелган. Мәдрәсә тәмамлагач, Миңлесорур апа балаларны җыеп, башта мәчеттә укыта башлый. 2016 елда аның улы, кызы һәм Вафин атлы авылдашлары мәчеткә янкорма төзергә уйлый. Абыстай хаҗ кылырга китеп бара, ул кайтышка янкорманы матур итеп төзеп куялар да, мәдрәсә ачалар. Хәзер анда биш төркем дини белем ала. Балалар да, олылар да укырга теләп йөри. Имам Вагыйзь хәзрәт әйтүенчә, җомгаларга утызлап кеше йөри.

Шушы көннәрдә генә мәчет янында «Чишмә» дип аталган чиста су алу урыны ачылган. Мондый чишмәләр моңа кадәр Лаешның Габиш, Усад, Сокуры авылларында ачылган, Имәнкискәдәгесе – дүртенче нокта. Районның хакимият башлыгы Илдус Зарипов әйтүенчә, бу федераль проект та, республика проекты да түгел. Бу – райондагы эшмәкәр егетләрнең халыкны сулы итү өчен керткән өлеше, аларга халык бик рәхмәтле. «Чишмә» мәчетне дә матурлый, бисмиллалы чишмәдән эчкән суның шифасы да булыр», – ди хаким. Әлеге чишмәләрдән су 80-90 метр тирәнлектән чыгарыла, барлык анализлары алынган, фильтрация куелган. Мәчетләр янында су пунктлары ачу идеясенең авторы – шушы район егете, Казандагы реабилитация һәм адаптация үзәге директоры Азат Гайнетдинов.

КЕЧЕ ЕЛГА

Районның татар рухын саклап торучы иженче зур авылы – Кече Елга. Авыл уртасында безне «Театр» дигән язуы белән балкып утырган матур бина каршы алды. Гаҗәпләндек, башка авылларда – гадәти мәдәният сарайлары, ә монда –театр! Авылда озак еллардан бирле халык театры эшләп килә икән. Режиссеры – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Равилә ханым Вәлиуллина. 2018 елда бинага бик яхшы ремонт ясаганнар һәм халык театрын зурлап, театр дип атканнар. Бинаның эчке ягы шәһәр мәдәният сарайларына биргесез. 128 кешелек тамаша залы, сәхнә, репетиция бүлмәләре, музей экспозициясе, бию залы, бәдрәфләр, юыну бүлмәләре – барысы да заманча, күз явын алырлык. Театр елына ике спектакль куя, халык авылдашлары уйнаганны карарга зал тутырып килә. Кече Елгалылар гомумән каядыр читкә чыгып спектакль уйнарга яратмый, үзебезнең авылдашлар өчен куябыз, үзебездә уйныйбыз, безне монда яраталар, без монда кирәк, диләр. Шулай булса да, ел да «Идел-Йорт» фес-

● Имәнкискәдә яшәүче Һава апа Галләмова бакчасында сакланучы кабер ташы.

● Кече Елга театрында чигүле эшләнмәләрдән кызыклы күргәзмә оештырганнар.

тиваленә барып, үзләрен күрсәтеп кайталар икән. Мәдәният сараеның икенче катында авылдашлардан җыелган чигүле эшләнмәләрдән гаҗәеп бай күргәзмә оештырганнар. Монда сөйгәне сугыштан кайтмаган кызның бирнә сандыгыннан сөлге дә, намазны күп укыганнан юкарып сизрәгән намазлык та, хәтта кияү алъяпкычы да бар. Элек кызлар кияүгә чыкканда, ирләренә дип алъяпкыч чигеп алып килгән, яшь кияү йорт эшләре эшләргә шул чигүле киндер алъяпкычны ябынып чыга торган булган.

Кече Елгада татар урта мәктәбе бар, тик балалар саны гына елдан-ел кими бара. Мәктәптә быел нибары 37 бала укый... Кайчандыр сөт сатучылары белән дан алган авылда хәзер 400 ләп йортка 20 сыер тоталар. Сөт очсыз, икмәге кыйммәт, ди авыл кешеләре, сыер тотудан файда юк... Шәһәрнең якын булуы да файдага түгел, кала яшьләрне үзенә тарта. Быел гына өч балалы гаилә Казанга күченеп киткән, мәктәптә балалар саны кимегән.

Кече Елганың аягында нык басып торган, туган җирдән ямь табып яши торган эшлекле ирләре дә бар, шөкер. Гафур Зарипов – шуларның берсе. 2004 елдан бирле фермер. Җиденче буын умартачылар династиясен дәвам иттерүче дә ул. Башта колхозда умартачы булып торган. Фермерлык эшен пай җирләрен эшкәртүдән башлаган. Умарталык яныннан алган 30 га җир була ул. Тора-бара пай җирләрен сатып яисә арендага алып, майданны мең гектарга җиткергән. Арпа, бодай, атларга солы чәчә. Хәзер аның 4 комбайны, башка төр техникасы бар. Хуҗалыкта 30-40 баш ат бар. Җир эшкәртү белән беррәттән, ата-баба һөнәрен дә дәвам итә – урмандагы умарталыкларында 300ләп баш умарта тота. 20 елдан артык тәрбияче булып эшләгән Оркыя ханым – зур хуҗалыкта иренең уң кулы. Балны төргәкләтеп, матур савытларга тутырып та саталар. Зариповлар ике бала үстергән: кызлары сәүдә буенча укыган, уллары исә авыл хуҗалыгы институтында белем ала. Димәк, әти башлаган эшне дәвам итәрлек алмаш бар. Алтын башаклы, офыкка чаклы җәйрәгән кырда Гафурның 4 комбайны эшләп йөри. Икмәк уңышы быел мул чыга, хуҗа канәгать. Тик сатып алу бәясен генә бик түбән куйганнар – центнерына нибары 9 сум. Игенченең хезмәтенә лаеклы бәяме инде бу?..

Лаеш киң Чулман диңгезен тибрәндереп, көнбагыш кырларын чайкалдырып озатып калды. Юл буендагы чиркәү гөмбәзләрендә кояш балкый, борынгы Кашан шәһәре өстендә тургай сайрый иде.

Эльмира СИРАҖИ.

● Кече Елга фермеры Гафур Зарипов.

● Игорь Бурмистров талдан могҗиза ясый.

● Кече Елганың үз театры бар.

ЯЗМЫШЫҢА ЫШАН

(Ахыры. Башы 35 нче санда).

Борнашевның йөзе әлеге сүзләрдән яктырып китте. Ул, урынында утырып кала алмыйча, сикереп торды, озынча бүлмәсенең аргы башыннан урап килде.

– Соң бит, күптән шулай диләр аны, Айбулатов, баш катырып утырасың монда, – диде ул әңгәмәдәшенең җилкәсенә кулын салып. – Күптән шулай диләр аны, дускай... – Борнашев соңгы сүзгә аеруча басым ясап әйтте.

– Соң, сез бит миннән, Мирас Гайнанович, турыдан-туры: китәсеңме Казанга күчеп, әллә юкмы? – дип сорамадыгыз. Ничек инде мин үзем башлап әйтим... Чаллыярыбызны ничек ташлап китәсең дә, аннан башка ничек яшисең, ди.

Тагын телефон шылтырады. Борнашев урынына барып утырды, трубканы алды да бераз тыңлап торганнан соң, Айбулатовка борылды һәм учы белән микрофонны томалаган килеш:

– Әнә, Казан кунаклары сине югалтканнар, монда килмәкчеләр, – диде. Аннары яңадан трубкага: – Килегез, хәзер үк килегез, иптәшләр, – дип өстәде.

Бер минут чамасы тын тордылар. Борнашев тагын нәрсәдер әйтергә тели иде, шуңа күрә Айбулатов урыныннан кузгалмыйча көтеп торды.

– Беләсегез килсә, Фазыл Артышевич, минем үземнең дә борынгыдан килгән тарихи башкалабызның алама йортларын сүтеп, алар урынына Ташкент, Алма-Атадагы кебек күз явын алырдай йортлар, архитектура ансамбльләре төзисе килә дә бит. Ләкин әлегә бу эшләрне калдырып торырга туры килә. Халыкны торак белән тәэмин итәсе бар. Минемчә, Фазыл, килер шундый бер вакыт, без Казанның тарихи үзәген саклаган килеш, аның барлык матур сыйфатларын чагылдырган мемориаль булдырырбыз әле. Тар урамнар ел саен ремонтланып та аламалана барган иске йортларны шушы мемориаль эчендә генә калдырырбыз. Ә хәзергә... ә хәзергә без килер буыннар өчен Чаллыярны, Көмеш Аланнарны салырга тиешбез, Фазыл...

Җәйнең җылы киче, кояш инде Көмеш Алан ягындагы урман артына төшеп бара. Аксыл болытлар күк гөмбәзенең ерактагы читенә таба агылалар, ә Ширәмәт тавының текә битендәге агачлар кояшның иң соңгы нурларында коеналар иде.

Шифаханәнең ак бүлмәсе дару исләренә күмелгән. Кичке бакчаларда балан һәм гөлҗимеш алтынсуланып күренә. Чабып ташланган бәрәңге сабагының аз гына кыза башлаган исе борыннарны ярып керә, үпкәләргә кытыклап ала иде.

Гаяр больница ягына таба борылгач та, өй түрендәге бакчада эшләп йөрүче бер агайның: «Хатын үстерә бит аларны, ачуланыр...», – дип киреләнеп маташуына карамыйча, кызгылт миләүшә һәм ак роза чәчәкләре сатып алды. Хәзер ул Гөлфирә бүлмәсенә шуларны тотып, елмаеп килеп керде.

Ни хикмәттер, Гөлфирә, ак халатка төренгән Гаярның үзен таныганчы, чәчәк исен сизеп алды һәм ишек ягына таба борылды. Ул иркесездән:

– Ой, нинди тәмле, хуш ис... Бөтен һаваны үзгәртте, – дип куйды һәм соңгы көннәрдә ярыйсы гына җанланган күзләрен Гаярга күтәреп карады. Аның озын, матур керфекләре аша яшь бөртекләре саркып чыкты.

Гаяр шулай ук сүзнең алдын-артын уйлап тормыйча:

– Без булган җирдә һава шулай үзгәрүчән инде ул, –диде.

Беркавым тын торгач, Гөлфирә чәчәкләрне тумбочка өстендәге стаканнар янына куйды, аннары шелтәле күзләрен тутырып карады.

– Мактанырга ашыкма, иптәш Сәфәров, ашык... – дип, ярты юлда сүзен бүлде, һәм өстәлдә яткан чәчәкләр ягына борылып, аларның берсен, ак төстәгесен алып Гаярга сузды. – Мә, Гаяр, иснәп кара әле, бигрәк хуш исле бит...

Каршылыклы, бик каршылыклы тойгылар кичерә иде бу минутларда Гөлфирә. Гаярның ничә еллар буена беренче мәхәббәт хисләрен саклавы, аның әле хәзер дә теге чактагы, басма янындагы кебек дулкынлануы, Гөлфирәнең ярыйсы гына тапталган хисләреннән җавап көтүе сәер, бик сәер сыман иде.

Кем белә, бәлки, Гаяр теге вакытта үзенең хисләрен җавапсыз калдырып киткән кешедән үч алырга, аннан көләргә, үзенеке итәргә дә аннары...

«Юк, юк, мондый әшәке уй белән йөри торган кеше түгел бит Гаяр. Мин ул, мин пычрак җан, нигә мондый уйлар белән аның керсез сакланган хисләрен буярга тырышам соң мин», – дип уйлый иде Гөлфирә Гаяр белән соңгы очрашуны исенә төшереп. Ләкин андый минутларда, шушы уйларга тотынып диярлек Гөлфирәнең күз алдында теге вакытны, кочагына сирень чәчәкләре күтәреп, күзләрен ялтыратып басып торган Гаяр, аннары малайларча кызуланып, Гөлфирә үчен басма такталарыннан алуы искә төшә. Шулай итеп Гөлфирәнең уйлары эзлексезләнеп кала һәм ул төгәл бер карарга килә алмыйча бимазалана иде.

Гаяр да Гөлфирәнең дулкынлануын, күңелендәге кичерешләренең каршылыклы икәнлеген чамалый. Әчке бер сиземләү аңа Гөлфирәнең нәрсәдер әйтергә, ләкин әйтә алмыйча үз-үзе белән көрәшүен пышылдап тора шикелле.

Больницада инде аларның катлаулы язмыш кичергәннәрен чамалыйлар, врачлар һәм Лаксандра-Санук апалары да комачауламый, иркенләп сөйләшүләрен, ничәмә-ничә еллардан соң аңлашуларын телиләр иде.

Тыштагы эңгер-меңгер куерды, һава салкыная төште, август ае көзнең якынлашуын сиздерә иде. Хастаханә кешеләрнең күңелләрен нечкәртә, сизгеррәк итә. Гаярны күрүгә хәстәрләп куйган сүзләрен оныттымы, әллә онытмыйча, бары тик кыюлыгы җитенкерәмичәме:

– Килдеңме... Гаяр? –дип тынып калды Гөлфирә.

Килгәндә ул, Гөлфирәнең кулларыннан тотып, битләреннән үбеп алырга иде дип хыялланган иде, булдыра алмады.

– Килдем шул... Гөлфирә, –дип кенә чикләнде.

Бүлмәдә һич көтелмәгән, бу очракта бик тә урынсыз тынлык урнашты.

Тыштан тонык кына булып күк күкрәве ишетелде. Аннары чикләвек яшене Ширәмәт таулары өстен ялтыратып алды. Гаяр шунда гына, халат астында яшереп тоткан, күчтәнәч алмалар салынган полиэтилен капчыкны исенә төшерде.

– Менә, Гөлфирә, сиңа бригада кызлары җибәрде.

Ләкин бригада кызларында ул көнне күбесенә бөтенләй таныш булмаган «Гөлфирә апа» кайгысы юк иде.

– Алмакайлар...

Гөлфирә әллә кызларны, әллә, чынлап та, берсеннән-берсе ныграк алсуланган алмаларны шулай назлап атадымы, анысын Гаяр аңлап бетермәде, ләкин Гөлфирәнең сәер халәттә булуын чамалап алды.

Дөрес чамалаган иде ул.

Теге көннән соң Гөлфирә, башындагы чәчләре үрә торып чигә тамырлары кыса башлаганчы, Гаяр белән үз-үзен ничек тотасын, нәрсәләр сөйләшәсен уйлады. Уйлаган саен тирәнгәрәк керде, фикерләр каршылыгы көчәя барды, узгандагы вакыйгалар, бүтәнчә төсмерләр алып, астыртын яклары белән ачылды.

«Минем хәлләрне, бигрәк тә соңгыларын беләме-юкмы? Белсә, мине кызганып, кулдан-кулга китмәсен, йолып алыйм, начарлыгына каршы яхшылык эшлим дә үземнең көчлелегемне күрсәтим», – дип кенә йөрмиме икән соң ул дип иза чикте Гөлфирә.

Әммә шунда ук кемдер аның колагына: «Болай итеп япа-ялгызың күпме яшәргә була? Син дә тере кеше бит, гомерең, багалмасыдай яшь чакларың шулай очраклы кешеләр белән үтәрме? Теләсә нинди талымлы ир-атны да бәхетле итәрдәй кайнар тәнең шулай кадерсезләнер дә пыскып сүнәргә калырмы? Гомер дигән нәрсә, Гөлфирә, кешегә бары тик бер генә мәртәбә бирелә һәм аны бушка уздырмаска иде бит», – дип пышылдагандай булды.

Хәер, бәлки, берәү дә пышылдамагандыр, Гөлфирә күңелендәге уйлар шулай тел очында әйләнгән-бөтерелгәндер. Ничек булса булгандыр, беркөнне Гөлфирә әлеге очсыз-кырыйсыз уйларын, күңелсезлекләрен, бигрәк тә үзенең күргән-кичергәннәрен мыскалын да яшермичә Гаярга сөйләп бирергә дигән карарга килде.

Хәзер, бүлмәсенә Гаяр килеп кергәч тә, Гөлфирә әнә шушы сүзләрне, чишмә оясында тулып, улак буйлап җиргә түгелгән су сыман, актарып салырга әзер, ләкин нииндидер көч аның телен бәйләп куйган шикелле тотып тора, башлап китәргә ирек бирми иде.

Хәер, бүтән вакытта, җыелышларда яки киңәшмәләрдә, ир-ат арасында, бигрәк тә участоктагы эш мәйданында теле телгә йокмаган Гаяр да шундыйрак хәлдә иде бугай. Дөрес, ул инде ишек төбеннән Гөлфирә яткан карават янына килгән, урындык алып аның каршысына утырган иде утыруын.

– Ник, ник дәшмисең, Гаяр, нигә сөйләшмисең? – диде, ниһаять, Гөлфирә телен тотып торган нәрсәдән арынырга тырышып.

– Син, син үзең дә бүген әллә нинди бит, Гөлфирә. Күзләрең дә әллә нинди моңсу. Нәрсә булды дип сорамакчы идем менә...

Борынгы Ширәмәт тирәләре күк гөмбәзендә йөзгән болытлардан караңгыланып, беркадәр шомланып калганнар. Тау битләрендәге нарат урманы арасында анда-санда гына тупланып утырган чикләвек агачларын төнге яшеннең киң кылычы уңлы-суллы кыйнавын дәвам итә иде.

– Беләсеңме, Гаяр, – диде Гөлфирә, күк йөзенә таба төбәлгән килеш. –Теге вакытта, басма буенда, аннары мәктәптә дә синең күңелеңдәгене аңлаган идем бит мин. Әйе, әйе, беләсең килсә, синең кебек уңган, чибәр егетнең үземә гашыйк булып йөрүенә бик нык горурлана идем. Кызганычка каршы, ул чагында минем чая матурлыгыма кызыгып йөрүчеләр мәктәптә дә, мәктәпне бетереп чыккан авыл егетләре арасында да син генә түгел идең. Мин – хатын-кызга гына хас сыйфаттыр инде бу – үзенә күрә бер усал канлылык белән аларның башын әйләндерүдән кызык таба идем.

Гөлфирә, сөйләвеннән туктап, стакандагы чәйне вак-вак йотымлап эчте, иреннәрен тастымалга сөртте, күзләрен тутырып Гаярга карады, аннары көрсенеп, тирән сулыш алды да, ни булса да булыр дигәндәй, кулын изәде, сүзен өзелгән төшеннән ялгап китте. – Иң кызганычы, синнән кала, бүтәннәрнең берсе дә миңа ошамый, ләкин мин аларга игътибарлырак та, йомшаграк та, сүзчәнрәк тә идем... Ә син, син бит тыйнак идең, күңелеңдәге хисләрне әйтергә яхшысынмый идең. Бәлки, чын хис булганга әйтүе, күкрәгеңнән чыгарып салуы кыен тоелгандыр. Тик мин андый нечкәлекләрне аңлардай дәрәҗәдә түгел идем әле. Минем өчен бүгенге кыюлык – чынмы ул, әллә ялганмы – мөһимрәк иде. Мин синең чибәрлегеңне, миңа карата нииндидер башкаларныкына бер ягы белән дә охшамаган хисләр кичерүеңне күрә идем. Әммә, кем әйтмешли, күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе ботак тишегә дигәндәй...

Газиз КАШАПОВ

Үр талантка буйсына

Искиткеч матур, сирәк була торган бас тавышлы якташым Рөстәм Асаев белән беренче тапкыр моннан унбиш ел чамасы элек Казан дәүләт консерваториясе бинасында очрашырга туры килде. Мин аңа данлыклы якташларымны барлап, күренекле җырчы, профессор Зилә Даян кызы Сөнгатуллинаны эзләп килгәндә тап булдым. Гәрчә иҗат гомеремдә Башкортстан һәм Татарстанның йөзләгән сәнгать әһелләре хакында язарга туры килсә дә, мин моңа кош тоткандай сөендем. Һәрдаим аның елмаюлы йөзеннән сирпелгән нурлар, ихласлык беркемне дә битараф калдырмый. Гадилеге, авылча сөйләше шундук әсир итә. Ә сер сандыгын ачып, үткәннәргә бер караш ташласаң, ниләр генә сыймаган анда! Чагыштырмача яшь Рөстәмгә бормалы тормыш сукмагыннан атлаганда күңел түрендә гел кояш нурлары гына уйнамагандыр, болытлы, давыллы мизгелләре дә булгандыр. Дөнья бит ул...

Ул үзенең алдына бөек җитәрдәй генә изге максатлар куеп талпынды. Әткәй-әнкәсенең фәһемле киңәшләре, үзенең илаһи көче, дәрт-дәрманы, таланты аның барыр юлларында офыкларны киңәйтә. Ә бит барысы да тәүге сулыш алган, ялан тәпи йөгереп киткән туган җирләрдән башлана. Рөстәм дә «очар канатлар» куйган, Әмирхан Еники, Рим Хәсәнов кебек күренекле шәхесләр биргән төбәктә тууына шатлана да, чиксез горурлана да. Һәм «Бик сагындым сезне, якташлар», дип җырлап та җибәрә. Шунда инде гүзәл табигатьле Балышлы авылының иксез-чиксез иген басулары, урман-кыр, инешләре, шау-шулы мәктәп еллары күз алдына килеп баса. Гәрчә аның укытучысы Филзә Хәкимова булу (БДУда бер төркемдә укыдык) миндә кызыксыну уятты. Аның белән күптән очрашкан юк. Ә Рөстәм белән сирәк-мирәк очрашып, телефон аша аралашып торабыз. Берничә ел элек минем туган якта – Бишбүләк районында патриот шагыйрь Фатыйх Кәримнең юбилеенда очрашкан идек. Фотога да төштек. Баксаң, менә үзенең дә юбилее килеп җиткән икән. Яшь тә түгел, карт та түгел, нибары 45 кенә.

Артка әйләнеп карасаң, сагынып та, шатланып, моңсуланып та искә алыр чаклар бар. Авыл баласының да уй-хыяллары була. Бигрәк тә иҗатка омтылган кеше һәрвакыт эзләнеш мизгелләрен кичерә, яңалыкка, үсешкә омтыла. Заманында Башкортстан тамашачысы Рөстәм Асаевны Уфа сәнгать училищесыннан, сәнгать академиясеннән, ә туган ягы – Благовар районы Балышлы авылы халкы мәктәп чорыннан бирле җыр-моңга һәвәс, сәләтле яшь җырчы буларак кабул итә. Авылда үткәрелгән мәҗлесләрдә, кечкенә чакларда мич арасындагы чаршау артына качып-посып, татар-башкорт халык җырларын кемнәр генә тыңламады икән?! Әнә шулар барысы да буыннан-буынга, кичәдән бүгенгегә күчә килгәндер дә инде.

Рөстәм Асаевның да күңелен кечкенәдән әнә шул сихри моң биләп ала. Үсмер чактагы хыялларын тормышка ашыра. Нәтиҗәдә, махсус сәнгать уку йортларын уңышлы тәмамлап, узаңлы тормыш юлына баса. Башкортстанда яшәгән чорда да шактый гына концетларда видеоклиплар яздыртуда катнаша, матур гына уңышларга ирешә.

Еллар үтү белән аның күңеле нурлы, моңлы Казанга тартыла, үсешкә омтыла. Рөстәмгә бер үк вакытта Казан дәүләт консерваториясендә аспирантурада уку, опера студиясе солисты, Казан шәһәр филармониясе җырчысы булу – барысы да җиңел генә бирелми. Әмма тырышудан туктамый ул.

Тора-бара Рөстәм борынгы, данлыклы Казанны үз итте, аны яулауга ирешә. Аның шау-гөр килеп торган урамнарыннан ул кыю адымнар белән атлый, сәхнәдә дә үзен ышанычлы тота. Ә бит кайберәүләр зур шәһәрдә югалып кала. Рөстәм исә җырмоң диңгезендә колач җәеп йөзә, иҗат үрләрен яулый. Аны кайда да беләләр, үз итәләр, күпләр тырышлыгына, гадилегенә дә соклана. Заманында аңа Казан дәүләт консерваториясендә студентларны укытырга туры килде. Гастрольләр еш булгач, билгеле, вакытка җайлашу кыен. Югыйсә, үзен Казан дәүләт мәдәният институтына да, музыка көллиятенә дә укытырга чакыралар. Әлегә ризалашмаган. Күрәсең, акча колы булып яшисе килми. Шуңа да, ул бер урында береге п, күңел биреп эшләүне хуп күрә. Моның нәтиҗәсе дә озак көттерми.

Вакыт дигәнең бик кыска булса да, Рөстәм аны дөрес итеп, нәтиҗәле, максатчан куллана. Иҗат мәйданында ныклы, ышанычлы басып торган, чәмчел сәнгать кешесенә чагыштырмача тиз вакыт эчендә фатир алу, шулай ук мактаулы исемнәргә лаек булу матур уңыш бит ул. Моның белән ул Казан шәһәре филармониясенә, аны үз иткән, яраткан тамашачысына олы рәхмәтле.

Бер уңайдан Рөстәм Мәҗит улының күркәм сыйфатларыннан: ярдәмчеллеген, эчкерсезлеген, изге күңелле булуын искә алмый мөмкин түгел. Берничә ел элек Казанда Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан шаулап үткәрелгән иҗат кичәмдә минем якташларым: халык шагыйре Рәдиф Гаташ, Татарстанның атказанган артисты Гөлнара Тимерҗанова, җырчы, композитор Илшат Вәлиев һ.б. иҗат әһелләре белән беррәттән, Рөстәм Асаев та үзенең дәртле җырлары белән катнашкан иде. Алай гына да түгел, авылда сабантуй үткәрүдә, мәчет төзү эшләрендә ярдәм кулы суза. Якташымның мондый изгелеген, кадер-хөрмәтен ничек онытасың?!

Әйткәнемчә, без аның белән телефон аша еш аралашабыз. Ул юлда булса да: «Сөйләшә алмыйм», дими, хәлләребезне белешәбез. «Сөенечләре күбрәк булсын», – дибез дә оптимистик рухтагы хәбәрләргә күчәбез. Баксаң, быел яз айларында Рөстәмгә «Татарстан Республикасының халык артисты» исеме бирелгән икән. Аннан алдарак «Башкортстан Республикасының атказанган артисты» исеменә лаек булган иде. Сөенеч өстенә сөенеч бит. Болар – һәммәсе дә озак еллар тугандаш халыклар мәнфәгате өчен җаныңны фида кылып, йөрәк җылыңны биреп, яраткан эшеңне ихлас башкару нәтиҗәсе дип кабул итәргә кирәк. Шулай булмаса, ике республика халкы да, аларның җитәкчелеге дә сиңа шундый кадер-хөрмәт күрсәтер идемени?!

Сүз уңаеннан, Рөстәм халык, ретро җырлар белән опера, романс, классик җырларны да бердәй әһаңлы, оста итеп башкара. Гадәттә, без аның «Гармун моңы», «Яшәргә, иркәм, безгә», «Әдрән диңгез», «Киек казлар китә», «Сагынам авылымны», «Яндырма күперләреңне», «Батырларга», Татарстанның халык артисткасы Бәширә Насыйрова белән башкарган «Исеңдәме» җырларын сагынып көтәбез. Ә кызы Гөлназ белән бергә башкарган «Кышкы романс» җыры һәркем күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтәдер. Шулай ук Гөлназ үзе башкарган «Чулпан» җыры шәхсән күңелемне бик тә тетрәндерә. Рөстәмнең татар, башкорт, рус, итальян телләрендә җырлавы да күпләрне битараф калдырмый. Һәркайсын оста итеп, табигый тавышы белән башкара. Артистның сәхнәдә тотышын да, тыйнаклыгын да сизгер күңелле тамашачы тиз тотып ала. Үз чиратында Рөстәм дә моны тиз тоемлый. Югыйсә, соңгы вакытта, бигрәк тә талантсызлар тыйнаклык, чама төшенчәләрен санга сукмый, әрсезләр юлына баса – түрле исемнәр алуга да ирешәләр хәтта. Гадәттә, халык аларның чыгышларына битараф кала.

Бу яктан исә Рөстәм Асаевның күңеле дә, намусы да саф. Җигелеп, җиренә җиткереп эшләргә ярата. Кайберәүләр кебек клиплар төшертү белән дә мавыкмый. Шунысы сөенечле: әтисе Мәҗит исән чакта әнисе Рәмзилә катнашлыгында ямьле җәйге чорда «Бәхет» исемле клип төшерелә. Соңгы истәлек булып мәңгегә калды. Анда әтисенең техниканы яратуы, өздереп баянда уйнавы, хәзрәт буларак Коръән укуы, әнисенең йорт-курада мәш килүе чагылыш таба. Рөстәмнең таудан авылының матурлыгына сокланып: «Бәхет бит ул әтиәни сине туган йортта көтеп торса», – дип җырлавы гына да ни тора!

Ни үкенеч, коронавирус зәхмәте әтисен 70 яшендә бу якты дөньядан алып киткән. Рөстәм бу югалтуны бик авыр кичерде.

Аяныч, Гөлназ белән Вилданның улын күрә алмады. Шунысы да үкенечле: Рөстәмнең ноябрьдәге концерты да үткәрелми калды. Әмма тормыш дәвам итә, ә ул гомер иткән юлдашың-тормыш иптәшең, балалары белән матур. Гөлназдан кала, Айгөл белән алар Мөслимне, Әминәне, Хәбилне тәрбияли. Күренекле җырчыга олы хөрмәт йөзеннән бер улларына Мөслим Магомаевның исемен кушканнар. Рөстәм аны үзенең кумиры дип исәпли. Шулай ук якташы, 32 яшендә РСФСРның халык артисты исеменә лаек булган мәшһүр җырчы Радик Гәрәевны да үзенең остазы дип кабул итә. Шуңа да ул, аларның репертуарындагы кайбер җырларны хөрмәт йөзеннән бар булмышын эшкә җигеп, ихлас башкарырга тырыша. Бу күренекле артистларның рухы алдында баш июедер, бәлки.

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ.

ХАЛЫКНЫҢ

Алмаз Хәмзинне белмәгән татар юктыр. Ә кем соң ул шулай да: сүз остасымы, җырчымы, әллә язучымы? Бар якны да булдыра бит үзе – сөйли башласа, авызына карата, баянын уйнап җырлап җибәрсә, кайбер җырчы аты күтәреп йөрүчеләр көнләшерлек! Каләм иясе дә бит үзе, Язучылар берлеге әгъзасы, «Чаян» журналы мөхәррире. Димәк, Алмаз Хәмзиннең татар дөньясында, татар күңелендә аулаган үз урыны бар. Борынгырак заман булса, аны чичән дип йөртерләр иде. Чөнки Алмаз – халкыбызның хакыйкатьне шаян-шук сүзгә төреп әйтә торган, җор һәм җырлы күңелле бер чичәне! Ә чичәннәр картаймый, алар яшәгән саен шомара, остара гына бара. Аңа карап, тиздән шушы ир солтаны 75 ен тутыра дип кем әйтсен инде? Әмма үзе белән кара-каршы утырып гәп корырга кулай сәбәп. Сүзен ерактан, балачактан ук башлады ул.

● Бөгелмә районы Карабаш мәктәбендә очрашу.

ТАШЛЫК - БӨТЕН АВЫЛГА БАШЛЫК

Түбән Кама районының Ташлык дигән авылыннан бит мин. Без балачакта «Ташлык - бөтен авылга башлык» дип мактанып йөри идек. Разил Вәлиев белән бер авылдан без. Күрше авыл Шәңгәлче дип атала, анысы Зөлфәт Хәким, Рафаэль Сәхәби авылы. Табигать шәп, Зәй елгасы ага, әрәмәлек, күлләр, балык, урман, җиләк, чикләвек… Иң яхшы болытлар безнең авыл өстенә килеп туктый. Иң якты йолдызлар монда атыла. Кол Гали югы бу, аны шунда туган, шунда җирләнгән, диләр. Гаиләдә без дүрт малай үстек, мин өлкәне. Хәзер төп йортта энекәш яши. Кайчагында әни ачулана да иде, ичмасам, ник берегез кыз булып тумаган шунда, дип.

Әни башлангыч классларда укытучы булып эшли. 4 сыйныфка кырыклап бала, мәчеттә урнашкан мәктәптә укыйбыз. Әти партком секретаре булса да, мәчеттәге манара исән торды, беркайчан да кистермәде. Шулай беркөн әни эштән кайтты, эти чүпләргә дип бәрәңге казып калдырган иде. Кара болыт килә, әни казылган бәрәңгене тизрәк чүплик, дип ашыктыра. Ә минем уйнарга чыгасы, эштән таясы килә. Әни шунда үсеп утырган көнбагышны төбе-тамыры белән йолкып алды да сыртка китереп кундырды. Мин шул минутта ук, җирдән капшый-капшый, бәрәңгене җыя да башладым. Азрак аң керде, әнигә күпме борчу китерүемне аңлагандай булдым.

ЯЗАМ ДА ЕРТЫП АТАМ…

Унбер ел буе Разил белән бер партада утырдык. Өчәр кешелек парталар, карага манып язабыз. Ул чакта әле матур язу дәресләре бар, шуңа ахры, почерк яхшы минем. Дүрт сыйныфны авылда укыгач, Шәңгәлчегә йөреп 8 не бетердек. Түбән Кама шәһәрен сала башлаганнар иде, укуны дәвам итәргә шунда киттек. Авылда гел дуртка-бишкә укып йөргән малайлар «өчкә» төшеп беттек. Русчабыз өчле-тугызлы гына, математиканы аңлатып бирүе бигрәк читен. Өйрәндек. Буйга озын шәһәр малайлары волейболны оста уйный, ә без төптән нык, эшләп үскән авыл малайлары, 110га 10 белән җиңеләбез. Тик чыгарылыш елны без аларны шул ук исәп белән җиңә башладык, чөнки безнең сулыш киң. Укытучылар белән дә дуслашып беттек. Класс җитәкчебез Зыятдин абый баянда шәп уйный иде. Хорда бөтен Сәйдәш репертуарын җырлыйбыз, мин башлап җибәрәм. Разил миннән күреп баянга өйрәнде, мин аңа ияреп шигырь яза башладым. Яз җиткәч, мәхәббәт шигырьләре бигрәк тә шәп язила иде. Тик язганны кешегә күрсәтү юк, оялам, кеше күргәнче дип ертып ата идем. Шулай итеп мәктәпне тәмамладык һәм… авыл хуҗалыгы институтына керергә дип Казанга киттем. Ни өчен авыл хуҗалыгынамы?..

ӘТИ САЙЛАГАН ЮЛ

Әти минем документларны авыл хуҗалыгы институтыннан килгән инструкторларга биреп җибәргән. Элек шулай авыллардан укырга кеше җыеп йөриләр иде. Әти мине колхоз рәисе итәргә тели. Ә минем Культпросветка керәсе килә… «Җүнле һөнәр түгел, йөрмә», - диде әти һәм мин аны тыңлап, институтка имтиханнар бирергә чыгып киттем. Авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына барып кердем. Ел ярым укыдым анда. Баянда уйнау, һаман җыр, бию белән мавыктым. Бию буенча фестивальләрдә җиңеп кайттык әле. Күңел ятмый бит укуга, ярты ел эленке-салынкы йөрдем дә, төзелеш институтына күчтем. Ике институт арасында балта остасы булып цирк та төзеп йөрдем әле. Бабай белән шабашкага йөреп тупланган тәҗрибә бар иде… Ел ярым укыган идем, повестка килде. Бар, Хәмзин, җүләр, армиягә барып акыл җыеп кайт! Киттем армиягә. Тәмамланмаган югары белем белән мине ракета гаскәрләренә алдылар. Грузиядәге космик үзәктәге хәрби учреждениедә секретчик булып хезмәт иттем. Ягъни космик объектларның очышы белән бәйле яшерен документлар өчен җаваплы кеше. Стройга җырларга кирәк булса гына чыга идем.

ҮЗЕМ САЙЛАГАН ЮЛ

Ике елны хезмәт итеп кайтсам, сөйгән яр кияүгә чыккан, көмәнле. Киттем пединститутның музфагына. Мин солдат киемендә, чәч тә коелып бетә язган. Музыкаль белемем юк, нота танымыйм. Баянда уйнатылар, күптән тотмагач, әллә ни шәп чыкмады бугай. Җырларга куштылар. Армиядә Илһам абыйның «Кара урман»ын өйрәнеп яткан идем, шуны сузып җибәрдем. Әзерлек курсына алдылар. Уку йорты тарихында музыкаль белемсез кабул ителгән бердәнбер кешедер әле мин, бәлки. Шулай итеп, 26 яшемдә нота танырга өйрәндем. Укыдым да, концертлар белән дә йөрдем. Бала-чага арасында укып чыктым шулай, гомергә минем дуслар да бала-чага булды. Укыганда ук «Саз» ансамблендә дә җырлыйм бит әле. Анда 13 ел җырладым. Бервакыт шулай «Саз» белән Мәскәүгә, Бөтенсоюз конкурсына киттек тә, институттагы чыгарылыш имтиханына чак кына кайтып өлгердем. Ансамбльдә җырлаганда консерваториягә дә чакырганнар иде, тик инде өченче уку йортын ташлап китмим, музфакны укып бетерәм дип, анысыннан баш тартырга туры килде. Баш та пеләшләнгән инде, консерваториядә тагын җиде ел укысам, пенсиягә дә ерак калмый, дидем.

СОҢЛАГАН ФАТИХА

Әти минем персидәтел булып

БЕР АЛМАЗЫ

кайтудан өметен өзгән иде. Шулай бервакыт ул Казанга килеп төште, ә минем кич белән концертта чыгыш. Аңа әйтмичә чыгып китә алмыйм, «Әти, минем кич белән концерт, барасыңмы?» – дим. Бармаганын белеп әйтәм бит, гомерендә йөрмәгән кеше. Ләкин «барам» диде бу. Коелдым да төштем. Сәхнәгә чыкканчы, бик дулкынландым, тик ничектер Ходай ярдәм итте, чыгар алдыннан тынычландым да әйбәт кенә җырладым. Тәнәфестә чыктым, әтине эзлим. Әти – Ватан сугышы инвалиды, протез белән йөри. Фойе буйлап протезларын шыгырдатып килә бу. Кулын бирде дә: «Улым, мин сиңа гомер буе комачаулаганмын икән...» – диде. Теге чакта ук Культпросветка киткән булсам, инде симфонияләр язып яткан булыр идем, бәлки.

ӨЙЛӘНҮ ТУРЫНДА

Укып бетергәнче, 32 яшемдә өйләндем мин. «Саз»дагы яңа килгән Тәнзилә исемле кызга күзем төште. Мин бер кешене генә ярата торган ир-ат, бишәр ел бер кешене оныта алмый йөри алам… Моны күрдем дә, бу кыз минеке, дидем. Мин филармониягә эшкә күчтем. Гастрольләргә яз көне китәм, көз кайтам. Киткәндә, кыздан сорыйм: миңа кияүгә чыгасыңмы? «Юк, минем егетем бар», – ди. Кайтам, янына барам, тагын сорыйм: миңа кияүгә чыгасыңмы? Җавап шул ук: «Юк». Тагын китеп барам гастрольләргә. Кайтам, сорыйм. «Чыгам», – ди бу өченчесендә. Үзем дә аптырап киттем, бу җавапны көтмәгән бит. Ярар, минәйтәм, менә сиңа акча, күлмәк, туфли, балдаклар ал, мин кайтуга әзер булып тор, дидем дә, тагын гастрольгә чыгып киттем. Кайтышыма барысын да алып куйган. Язылыштык та, 5 апрельдә дусларны җыеп (Рафаэль Сәхәби, Разил, Римма Ибраһимова, энекәшләр, хатынның туганнары), апаның 17 кв. метрлы коммуналка бүлмәсендә туй кебек мәҗлес үткәреп алдык. Рафаэль тамада булды. Өйләнүен өйләндем, ә яшәргә урын юк. Икебез ике тулай торакта. Болай булмый, аралар суынып алайса дип, Киров районындагы бер апа белән бүлмә сөйләшеп, аңа өйдәш булып яши башладык. Бернәрсәбез юк. Мичснә яга торган гади генә йорт. Беренче бала Алия дә, икенчесе Гадел дә шунда туды. Аннары гына Губкин урамындагы тулай торактан 9 кв метрлы бүлмә бирделәр. Филармониядә минем бригадада булачак халык артистлары: Хәнәви Шәйдуллин, Рабига Сибгатуллина, Нәфисә Васыйловалар… Җитәкчелеккә кереп фатир сорап караган идем, әлегә күренми, берәр җае чыгар әле, китмә, диделәр. Ләкин мин юк инде, фатирсыз килеш гастрольләрдә йөри алмыйм, дип филармониядән китеп бардым. Җиде ай үтмәде, филармониягә Батыршин урамындагы йорттан кооператив фатирлар бирделәр. Мин исә 10 елдан соң гына фатирлы булдым. Тугыз квадратлы бүлмәдән башта шул ук тулай торактагы 17 метрлысына күчтек. Беркая ялынып та йөрмәдем, беркемнең ишеген дә шакымадым. Фатирны исә «Комсомольское» мәдәният сараенда 10 ел эшләп алдым, 3 бүлмәлене. 43 яшемдә генә фатир ачкычын кесәгә салдым. Өч бала үстердек: Алия, Гадел, Алсу. Олылары музыка белемле, шул өлкәдә эшлиләр. Кечесе – икътисадчы, гаиләле. Сәид һәм Сәминә исемле ике оныгым бар. Хатыным заводта эшләде.

ОЗЫН ТЕЛ ӨЧЕН «КЫЕН» АШЫЙМ…

«Саз»да эшләгәндә концертларны алып баручы юк. Рифкать әйтә, үзең алып бар, ди. Шулай итеп, конферансье өчен кызыклар, юмор яза башладым. Шул кыска гына әйберләрдән башланып китте язу. Монологлар язам, үзем сәхнәдән укыйм. Аннары филармониядә режиссер булып эшләгәндә, сценарийлар күп язылды. Күп типкәләнгән кеше мин. Типкәләнмичә, сатира берничек тә туа алмый. Озын тел өчен «кыен» да ашарга туры килде, әлбәттә. Һаман да тыярга тырышалар: сәхнәгә чыксаң, чамалап сөйлә, телевидениедә артыгын ычкындыра күрмә! Хәзерге заманда эндәшмичә буйсынып яшәү милләтнең үлеменә якынаю ул. Мин бит революция ясарга маташмыйм, шушы хәзерге җитәкчеләрне бераз денгә кертәсе, алга барасы иде бит, дим. Үзең чиста булып, башкаларны да шуңа өндәргә, сүзеңне әйтергә кирәк. Ельцинның Казанга килгән чагы, чәкчәк тотып каршы алган кызларның арт якларын чәп-чәп иткән бу, янәсе шаяра. Мин исә моны сәхнәдә сөйләдем: депутатлар президентны мактар, президентлар кызлар капшар, дидем. Халык ду килеп кул чапты. Ахырдан мәгълүм бер җитәкче сәхнә артына керде: «Син нәрсә лыгырдыйсың? Кем булдың әле? Безнең президент турында әйтәсеңме син?» - ди. «Әгәр син аны безнең президент дип уйласаң, ялгышасың. Ул Татарстанныкы түгел», - дидем. Кулын селтәде дә чыгып китте. Артында торган тән сакчысы исә күкрәккә китереп ямады, сулышсыз калдым. Сүз әйтә алмыйм. Сәхнәгә чыгып әйтергәме икән мине кыйнадылар дип? Тик халык Хәмзин тагын шаярта дип шаркылдап көләр генә иде… Минем тел аркасында үзем генә түгел, балаларымның да проблемалары булганы бар.

МИЛЛӘТКӘ ЗАТЛЫ ЮМОР КИРӘК!

Мин телевидениедә күптөрле юмор тапшыруларын эшләдем: «Шаян-шоу», «Шаян сәхнә», «Ачык сәхнә»… Миңа алар популярлык, режиссерларга акча китерде. Аннары «Биш татар»ны оештырдык: Шәрәфи, Шамкай, Х.Җәләлов, Р.Сабиров, мин. Без чын, «элитный» юмор сөйли идек, ләкин мин киткәч, анда билдән түбән юмор башланды, акча эшләү юлына керделәр. Шулай берчак опера театрында «Бер кичтә 5 бенефис» дигән программа эшләдек, бер тамаша эчендә үзебезнең бенефисларны үткәрәбез, ягъни. Һәркайсыбызга 25 әр минут. Шамкайны да кысада тотам, бозык нәрсә сөйләтмим. Халык егылып кул чаба, кабат-кабат чакыра. Шамкай әйтә шунда: тагын бик сөйләр идем дә, сәхнә артыннан Хәмзин йодрык болгый, ди. Татарны күтәрер өчен затлы юмор да кирәк бүген.

Миннән еш кына: «Сез шулай да күбрәк кем: артистмы, җырчымы, язучымы?» – дип сорыйлар. Мин үземне Аз-маз Хәмзин дип йөрим. Аз-маз язучылыгы да бар, артистлык та, җырчылык та. Әле балачакта рәссам булырга да теләгән идем… Хәтта җиде ел стенада эленеп торган тальянда да үзлегемнән уйнарга өйрәндем. «Умырзая» көен чыгара гына башлаган идем, әти «Булдырасың, улым» дип, икенче көнне үк хромка алып кайтып тоттырды…

Эльмира СИРАҖИ
әзерләде.

Иманлы әсәрләр бәйгесе

Россия ислам институтында XI «Якупов укулары» узды. Якупов укуларында «Таян Аллаһка» бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү булды.

«Таян Аллаһка» бөтенроссия әдәби бәйгесе 2010 елда Вәлиулла Якупов тарафыннан башланып җибәрелгән иде. Бәйгене Татарстан мөфтияте Россия ислам институты һәм «Идел» журналы белән берлектә татарлар арасында талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатыннан үткәрә.

Конкурста Россиядә яшәүче 10 яшьтән алып 45 яшькә кадәрге теләгән һәр кеше катнаша алды. Төп шарт – иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнүче булмаулары. Конкурсның быелгы өстенлекле темасы Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы булды.

Конкурс февраль аенда игълан ителде һәм өч номинациядә үтте: шигърият, чәчмә әсәр һәм публицистика. Конкурсның 8 җиңүчесе бүген Якупов укуларында дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр алды.

«Таян Аллаһка» әдәби конкурсының 2021-2022 елгы йомгаклары:

МАХСУС БҮЛӘК – Юсупова Рәмзия Рәүф кызы (Казан шәһәре).

ШИГЪРИЯТ:

1 урын – Галиева Гөләндәм Исрафил кызы (Түбән Кама шәһәре).

2 урын – Халикова Нурфия Райнур кызы (Казан шәһәре).

3 урын – Хәйруллина Гөлназ Әхәт кызы һәм Гаязова Нурия Тәлгать кызы (Казан шәһәре).

ЧӘЧМӘ ӘСӘР:

1 урын – Фәнис Низамов-Думави (Аксубай районы).

2 урын – Галиева Райлә Муллаян кызы (Әтнә районы).

3 урын – Мәссарова Гөлназ Җәүдәт кызы (Чирмешән районы).

ПУБЛИЦИСТИКА:

1 урын – Фәттахова Лилия Тәлгать кызы (Лаеш районы).

2 урын – Курманова Илүзә Фирдәүс кызы (Казан шәһәре).



ФӘКАТЬ

Таушалган калыпларга сыешырга атлыгып тормаган бу кеше белән сөйләшкәч, иң әүвәл Г.Тукайның «Ләззәт нәрсәдә?» шигыре искә төште:
«Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт миндә бар.
Минемчә, монда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!»

Дөньядагы иң күләмле Ethnologue телләр каталогына 2020 елда Җир шарында 142 тел бердәмлегенә караучы 7174 тел теркәлгән. Әмма кешелекнең якынча өчтән икесе кырык телдә генә сөйләшә. Шул ук вакытта, ни кызганыч, Җир шарында инде берничә кеше генә сөйләшүче телләр хәттин ашкан... Югыйсә, тел байлыгын саклау буенча оешмалар – бихисап! Ә менә бу оешмаларга кермичә генә, алар эшләргә тиешленең бер өлешен үз өстенә алган аз санлы ирекмәннәрне... әлегә санап чыккан кеше булмады. Шуңа күрә бу тыйнак статистиканы милләттәшебез, Чаллыда гомер кичерүче Фәһим Җиһаншиннан башларга булдым. Ул – дөньяның иң зур күптелле халыкара аңлатмалы аудиосүзлеге булган forvo.com сайтында татар телен җан фәрман алга этәрүче ике кешенең берсе икән. Үзе әйтмешли, «теләсә кем белән аралашканда да һәрвакыт берлек сандагы» татар кешесе.

– Фәһим абый, forvo.com веб-сайты хакында сөйләсәгез иде. Аны ничек эзләп таптыгыз?

– Бик үзенчәлекле сайт бу. Сүзләр фонотекасы. Ул 2008 елдан бирле гамәлдә. Сайтның баш офисы Испаниянең Сан-Себастьян каласында урнашкан. Ул тулысынча иганәчеләр хисабына көн күрә, үзе коммерция белән шөгыльләнми. Аның интерфейсы татар теленә дә тәрҗемә ителгән. Мондый мөмкинлек сайтта чикләнмәгән – админнар тәрҗемә итү тәкъдимен мөхәррирлек статусын алган бөтен кешегә дә юллый. Ләкин әлегә бәйсез дәүләте булмаган халыклардан, татарлардан кала, бары тик каталоннар, басклар һәм көрдләр генә әлеге эшне өлешчә башкарып чыга алды. Татар интерфейсы исә – тулысынча тәрҗемә кылынган бердәнбер «бәйсез булмаган арадаш өсйөзлек».

Forvo сүзләр, сүзтезмәләр һәм аларның кулланылышын чагылдырган гыйбарәләр-җөмләләр әйтелеше базасын туплый. Болар язылган MP3 файлларын күчереп тә алырга мөмкин. Нинди дә булса телне яисә диалектны өстәргә теләп сайт администраторларына мөрәҗәгать итү мөмкинлегенә дә бар... Интерфейста «Эзләү»гә басып, кирәкле сүзне яисә сүзтезмәне язасыз да, әгәр дә бу сүз базада булса, ул зәңгәр өчпочмак билгесе белән берлектә күренә. Өчпочмакка баскач та, аның әйтелешен ишетеп була. Ә менә сүзнең үзенә баскач, аның кем, кайсы дәүләт кешесе тарафыннан әйтелүен, дәүләтнең кайда урнашуын да белергә мөмкин. Бер үк сүз төрле телләрдә төрлечә дә яңгырый ала, билгеле... Ул дөньяның алга киткән илләрендә һәм ишле халыклар тарафында аеруча популяр. Әлеге базада ирекмәннәр тарафыннан 400 телдәге сүзләр тупланган. Кешеләрнең исем-фамилияләре, математик символларның, саннарның әйтелешләре дә бар...

Казаннан Шамил исемле татар кешесе белән бергә әлеге аудиосүзлекне татар теле сүзләре белән унбер ел дәвамында тулыландырып торабыз. Мин үзем бу эшкә бары тик лаеклы ялга чыккач, 2011 елны гына тотындым.

Сайт серверлары дөньяның дистәләгән каласында бар. Берсе элегрәк Мәскәүдә дә эшли иде, ләкин, ни хикмәт, 2022 ел башында, дәүләт Украинада «махсус операция»гә керешкәч, Мәскәү серверы аша бу сайтка көчле һөҗүмнәр башланды. Нәтиҗәдә Мәскәү серверы хәзер вакытлыча ябылган килеш, урыслар да, без татарлар да Стокгольм аша эшлибез. Югыйсә, бу сайт акылы камил булган беркемгә дә комачау түгел. Киресенчә! Минемчә, Татарстан 1990 еллардагы сәяси халәтенә кайта алса, Мәскәү серверын Казанга күчереп утырту зур проблема булмас иде. Аны тоту чыгымнары дәүләт өчен тиеннәр генә бит. Ә перспективасы һәм һәртөрле файдасы – исәпләп бетергесез!

Сайтның татар интерфейсына tt.forvo.com адресы буенча кереп була. Әлеге сайтның татар теле секциясенә 884 мең татар сүзе һәм кыска сүзтезмәсе, мәкаль-әйтемнәр, гади һәм «канатлы» гыйбарәләр кертелгән. Үзенә күрә «тел пирамидалары» барлыкка килә: шул «күпкырлыклар» эченнәге теләсә кайсы сүзне эзли башласаң, компьютер экранында югарыда атап үтелгәннәр барысы да пәйда була. Ягъни бу татар теленең тагын бер «дәреслеге»: файдалан һәм өйрән генә! Мин башка халыкара сайтларда да эшлим, ләкин аларда кеше берүзе генә зур нәтиҗәгә ирешә алмый. Ә «күләм» булмаса, алардагы урыныңны киңәйтү, дәрәҗәңне арттыру да мөмкин түгел. Әйтик, ни кызганыч, мин tatoeba.org сайты интерфейсын татар теленә тәрҗемә итүгә рөхсәт алалмадым әле.

– Бер лексик берәмлекне яздыру өчен ирекмәнгә күпме вакыт бирелә?

– Сайтта ялгызак сүзнең яисә кыскарак сүзтезмәләрнең әйтелешен яздыру өчен 2,5 секунд җитә. Озынрак берәмлекләрне яздыруга 5 секунд вакыт бирелә. Без дә шушы вакыт аралыгында, сүзне микрофонга әйтеп, сыйфатлы итеп яздырырга тырышабыз. Әгәр дә әйтелеш начар язылса яки пышылдап ишетелсә, өлешчә киселеп калса, аны тагын берничә тапкыр яздырып була. Сүзнең синонимын, башка телләргә тәрҗемәсен дә өстәргә мөмкин. Кулланучы тере сүзләрнең тулы картинасын күзаллый ала. Сайтның һәр бүлегендә даими һәм актив эшләүчеләргә шактый киң мөхәррирлек мөмкинлекләре бирелә, алар һәр язылган сүзне, гыйбарәне һәм җөмләне тикшереп бара. Актив кулланыштан чыккан һәм ясалма телләр дә читкә тибәрелми. Әйтик, латин сүзләрен, гадәттә, америкалылар, алманнар, итальяннар әйтеп яздыра. Ә эсперанто сүзләрен – кем бу телне өйрәнгән булса шулар.

– Һәрбер телдә цензурасыз лексика дигән өлеш бар. Әгәр дә бу сайтка кем дә булса сүгенү сүзләре яздырса?..

– Мондый сүзләрне яздыру тыелмый. Әмма алар орфографик хаталарсыз һәм орфоэпик дөреслектә булырга тиеш. Сайт администраторлары фикеренчә, теләсә кайсы сүз әңгәмә эчтәлеге буенча йә яхшы, йә начар мәгънәгә ия була ала. Әйтик, «чучка» сүзе... Аны бит төрлечә аңларга мөмкин.

Бу сорауны Forvo порталының яңа кулланучылары гел биреп кенә тора. Гадәттә мин, аларга җавап биргәндә, Губерман «гариги» тәрҗемәсен дә тәкъдим итәм:

«Танытты илне дөньяга
Русиянең йоласы:
«Х..» дип яза ул коймага,
Төзелгәнче үк коймасы».

Шуннан соң кешенең цензурасызлыкка һәвәслеге бермә-бер кими.

– Бу платформа үзләрен лингвистика өлкәсендә тапканнар өчен ни дәрәҗәдә файдалы?

– Югары уку йорты студентлары өчен бу платформаның, һичшиксез, файдасы бар. Мәсәлән, практик яисә теоретик күнекмәләр вакытында, сүз әйтелешен анализлаганда... Мин үзем, 2011 елда эшкә керешер алдыннан, Равия Абдуллинаның «Риторика һәм интонация» исемле монографиясен укып чыктым. Равия ханым бу тиңдәшсез дәреслекне 1999 елда «Нур» газетасы редакциясенә бүләк иткән иде. Ләкин аңа каршы: «Нәрсәгә кирәк соң бу безгә, без бит радиочылар түгел, язучы журналистлар!» – диючеләр булды. Шыпырт кына монографияне мөхәррир Зәки абый Хәнәфиевтән сорап алдым да... «хосусыйлаштырдым». Унике ел үткәч, бу китап минем юл күрсәткечем булып китте. Дөнья булгач, бөтен нәрсә кирәк икән шул! Хәтта безнең ашкынып кулланулы дөнья ахырзаман көткәндә, күпчелек «файдасыз» дип санаган (шул җөмләдән, кайбер «галимнәр» дә!), ни авызга тыгып, ни кесәгә салып булмый торган forvo.com сайты да...

Сайт башка телне үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен җайлы. Аннары ул планетаның бар дәүләтләрендәге сүз әйтелеше күнекмәләрен үз итүче актёр-

МИЛЛӘТКӘ ХЕЗМӘТКӘ...



Аңлатмалар һәм сылтамалар һәммәсе дә ана телебездә язылганга күрә, мондый сүзлекләргә татар телен инде оныта да башлаган кешеләр, читтә яшәүчеләр ешрак мөрәҗәгать итәр дип уйлыйм. Үзем дә шундый хәлдә булдым: 13 ел буе читтә яшәргә туры килде. Сайт бушлай да бит әле. Аннары әлеге сайтта татар теле лексикасын туры-туры, рус теленә бәйләмичә өйрәнеп була. Әйтик, чит дәүләттә гомер итүче берәр милләттәшебез рус телен белми икән, аңа татар теле белемен ларның күбесе күчереп алу өчен түләүле, ә минем аларны юнәтергә «электрон янчыгым» юк һәм була да алмый. Мөмкин булганны аннан-моннан йолкып, бушлай чәлдерәм...

Сайт милли атамаларны да кабул итә, дөньякүләм танылырлык шәхесләребез исемнәрен дә, җирле топонимиканы да. Беркемне дә, бернәрсәне дә читкә тибәрмибез: Аллаһы Тәгалә кемнедер һәм нәрсәнедер барлыкка китергән икән, димәк, боларның кешелек тормышы өчен ниндидер хаҗәте бар.

Башта миңа суперредактор дигән остазлар беркеткәннәр иде. Беренчесе Киев кешесе булды, украин милләтле. Аннары... Нигерда яшәүче дип теркәлгән бер мәскәүле үз теләге белән минем «шефым» булып китте, һәм ул... минем 100 мең татар сүземне бетереп ташлады. Барыннан да бигрәк татар топонимикасын һәм тезмә-кушма фигыльләребезне сөймәде. Татар теленең кайсы тамырына балта чабарга кирәген аңлый иде ул. Мин сайт җитәкчеләренә: «Татар теле базасын

лар, журналистлар, дикторлар өчен дә уңайлы.

– Forvo сайты тагын нинди мөмкинлекләр бирә?

– Анда төрле телләрдәге, төрле хәлләр өчен яраклы һәм файдалы фразалар да тупланган. Мәсәлән, сәяхәт иткәндә, табибкә барганда, әйберләр сатып алганда... Яисә бер генә төрле темага яраклы сүзләр тупланмаларын гына да табып була, әйтик, транспорт буенча... Сәфәр алдыннан бу бүлекне ачасың да кирәкле сүзләрне исеңә төшерәсең.

– Фәһим абый, сезнең, ике татар ирекмәненең, уңышлары зурданмы?

– 2015 елдан алып, татар теле Forvo рейтинглары буенча беренче урында. Сайтның башка кулланылышлары да юк түгел. Телләге булган кеше татар сүзләрен, сүзтезмәләрне җирле сөйләмдә, диалектларда да әйтеп яздыра ала. Өлкәнрәкләр өчен башка телләрне пассив өйрәнү, балаларны чит телләргә күнектерә башлау мөмкинлекләре дисеңме...

тирәнәйтү өчен «арадашлык»ның кирәге дә калмый.

Татар телен җитди рәвештә өйрәнә башлаучылар да бу сайтны үз итә һәм аның әһәмиятен киләчәк буыннар белән бәйли алыр иде. Мәгънәсез һәм кыска гомерле «глобальләштерү»гә каршылык күрсәтү өчен дә булдырылган инде бу эш. Көнбатышта моны бик яхшы аңлаучы даирәләр булуын чын күңелдән хуплыйм!

Татар әдәбияты классиклары әсәрләреннән җөмләләр, бүгенге прозабыз һәм шигъриятебез мисаллары, табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр – ягъни татар халкының алтын мирасы, тел мирасы – берсе дә безнең өчен чит түгел бу сайтта! Кол Галидән башлап барысы да кадерле!

– Нигездә нинди чыганаклар белән эшлисез?

– Минем өчен «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан» журналлары – иң әһәмиятле чыганаклардан. Газеталар арасыннан иң көчле эчтәлеклесе – «Мәдәни җомга». Ни кызганыч, татар телендәге чыганак-

– Сезгә, вакытыңны бушка уздырасың, диючеләр дә табыладыр...

– Андый «киңәшләрне» ишетергә туры килгәләде. Икебезгә дә. Тик шунысы да бар: рухи җимереклек, һәртөрле аска тәгәрәүләр, милли инкыйразлар ялкаурак бәндәләр куйган бер үк сораудан башлана бит инде ул: «Кемгә һәм нәрсәгә кирәк соң бу?!» Кабатлап әйтәм: кирәк барысы да, дөнья булгач! Әйтик, яһүдләр моны бик яхшы аңлый, шуңа алар «дөнья тотучы халык» (Фоат Уразайга ияреп әйтүем!) дип санала.

– Сез бу сайт буенча кемнәр белән дус?

– Билгеле, әлегә кадәр без чит ил һәм чит тел кешеләреннән күбрәк ярдәм алдык. Ун ел элек рус теле секциясендә эшләгән Александр Петелин миңа эш барышын күпкә җиңеләйтүче, зур текстларны эшкәртү өчен уңай булган программалар юллаган иде. Сайтны төзүчеләр миннән аның рәсми интерфейсын, мәгълүматларын татарчага тәрҗемә итеп бирүемне үтенде.

киңәйтергә мөмкинлек һәм миңа мөстәкыйльлек бирегез», дип хатлар юлладым. Алар минем тәкъдимнәрем белән ризалашты. Теге мәскәүлене сайттан кудылар.

Алман ирекмәннәре миңа шул явыз кеше җуйдырган татар сүзләрен сайтка киредән кайтарырга булышты. Аеручa Канадада яшәүче, алман милләтле 80 яшьлек Вольфганг Һофмайерга рәхмәтлемен. Гомумән, «пандемия»гә кадәр без барыбыз да туганнарча аралашып эшләдек бу сайтта. Хәзер хәлләр үзгәрде, уңай якка түгел. Күбебезне төшенкелек басты. «Ә мәңгелекме соң бу шайтан вәсвәсәсе!» – дияр идем.

Мин үзем хәзер җиде телдә эшләү мөмкинлеген алдым: татар, рус, алман, инглиз, мари, башкорт һәм борынгы төрки телләрдә. Мин бу өстенлектән бик сак файдаланам: бернинди дәгъва булдырмаслык һәм татарларга файда китерерлек итеп кенә.

– Эшчәнлегегездә латин язуын кулланасызмы соң?

— Сайтта фәнни хезмәтләр өчен кабул ителгән заманча латин язуын да кулланабыз. Хәтерегездәдер, элегрәк Дәүләт Думасы «Заманәлиф-2012» имласын тыйган иде: «Россиянең бөтенлегенә каршы килә», имеш. Шуннан соң дистә ел үтте, ә империя әле һаман да исән! Әллә, мәйтәм, Дума бик белдексез булып чыкты, әллә без тәмам эшлексез булып киттек. Бәлки Тукай да «без... үлгәнме, йоклаган гынамы» дигән сүзләре белән хаклыдыр...

Моннан кала без татар сүзләренең инглиз, төрек, алман, вьетнам телләренә тәрҗемәсен дә урнаштырып барабыз. Бу хезмәтнең очы-кырые юк шикелле. Чөнки безнең секциядә миллион берәмлек тә тупланмады бит әле. Менә бер миллион сүз туплагач, татар секциясен сыйфатлырак итү турында да ныгытып кайгыртa алыр идек.

– Сайт администраторлары сезгә нинди дә булса башка төр тәкъдимнәр белән дә чыктымы?

– Шунысы куанычлы, сайтта борынгы һәм юкка чыкканнар исемлегендәге телләрне дә үстерергә тырышалар. Мәсәлән, администраторлар безгә борынгы төрки тел базасын тулыландыру мөмкинлеген тәкъдим итте. Күп диалектлы, бихисап сөйләшле бөек тугандаш шивәләр берлегә булган ул чынбарлыкта! Башта ул Forvo сайтында төрекләр карамагына тапшырылган иде, ләкин алар моның белән бөтенләй шөгыйльләнмәде. Өстәвенә, Төркия чыганаклары борынгы язма һәм ташъязма истәлекләрне «хосусыйлаштырып» куйган. Әйтик, Йосыф Баласагуни ун гасыр элек борынгы уйгур телендә язган «Котадгу билик» (Игелекле белем) әсәре... хәзерге заман төрек язуына күчерелгән. Барысы да төрек калыбында, борынгы хәреф-авазларның икесе генә калган: Ңң (Ŋŋ) һәм Гъ (Ğğ). Кемнәрдер төрки дөньяда әле һаман да үзен генә бар дип белә...

Без исә гаделрәк, «алтын урталык»лы юлдан китәргә булдык: төп чыганак итеп совет галимнәре эшләгән һәм 1969 елда дөнья күргән «Древнетюркский словарь»ны сайладык. Борынгы сөйләш үзенчәлекләрен чагылдыру өчен өстәмә 15 хәреф һәм берничә аваз керттек. Хәзерге вакытта 15 мең сүз һәм җөмлә яздырттык инде. Безнең тупланмада теләсә кайсы төрки халык кешеләре дә – угызы да, кыпчагы, хакасы, тывалысы, сахаякуты да – үзләренең тирәндәге тамырларын күрә ала! Халыкларны дуслык һәм туганлык тарафында берләштерү – илаһи миссиябез. Аны үтәүдән баш тартсак, юкка чыгабыз. Бу хакта мәрхүм Рашат абый Сафинның күпләргә мәгълүм булган өч китабында аермачык итеп язылган бит. Бүген бу эстафета – «мәдәни җомгалы» Фоат Уразай кулында.

Билгеле, замана балаларының күбесе саф татарча сөйләшми яки акцент белән сөйләшә. Әмма алар арасында үз милләте тарихын, телен, мәдәниятен теләп өйрәнүчеләр дә бар. Төрле шигырь бәйгеләрендә катнашучылар саны артуы да моны раслый. Бүгенге көндә: «Безгә үз тамырларыбызны онытмаска гына кирәк!» дип искәртеп торучылар бары файдага гына.

– Сез дә, фикердәшегез Шамил әфәнде дә игелекле, саваплы гамәлләр кыласыз. Ә үзегез нинди булышлыкка мохтаҗ?

– Дистә еллык һәм тормышка ашмаган хыялым бар: егерме кеше сайтка кереп, көн саен бишәр генә сүз яздырып чыкса иде! ТЕЛӘКТӘШЛЕК ЙӨЗЕННӘН һәм «БЕЗ ИСӘН!» дип дөньяга әйтү өчен. Моңа ике минут вакыт та җитә. Бүтән берни дә кирәкми. Хәер, әгәр дә берәр татар бае шушы эшне дәвам итү өчен заманча компьютер яки ноутбук бүләк итсә, аңа мең рәхмәтле булыр идем. Берьюлы Тукайның югарыда телгә алынган соравына да төгәлрәк җавап алыр идек.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Репрессияләр

Атнаның сәяси мизгелләре

«Барысы да план буенча...»

Әле август ахырында гына Россия саклану министры С.Шойгу Украинада үткәрелә торган махсус хәрби операцияне (МХО), кыска гына итеп, барысы да план буенча бара, дип аңлаткан иде. Ә ул план катлаулы булып чыкты. Украина Коралллы көчләренең (УКК) Николаев һәм Кривой Рог ягыннан һөҗүмгә күчүе турында Россия саклану министрлыгы (РСМ) әле август ахырында ук әйтте. Тиздән алар Харьков юнәлешендә дә һөҗүмгә кузгалды. Узган атнада инде РСМ 6-10 сентябрь көннәрендә генә дә УКК бу юнәлешләрдә үзенең 4 меңнән артык сугышчысын югалтуы, яралылар саны 8 меңнән артып китүе, бик күп хәрби техника да юк ителүе турында белдерде. Атна азагына Россия гаскәрләре Балаклея, Изюм калалары һәм Купянск тимер юл станциясенең дә бер өлешен калдырып, Оскол елгасы аръягына чигенергә мәҗбүр булган. РСМның рәсми вәкиле генерал-лейтенант И.Канашенков әлеге хәлне: «Для достижения заявленных целей специальной военной операции по освобождению Донбасса принято решение перегруппировать российские войска, находящиеся в районах Балаклеи и Изюма для наращивания усилий на донецком направлении», – дип аңлатты.

МХО барышындагы мондый борылыш күпләрдә инде җитди сораулар да тудырды. Хәтта Чечня башлыгы Р.Кадыйров та, «зур хәрби белгеч» буларак, әгәр махсус хәрби операция үткәрү стратегиясенә бүген-иртәгә үзгәрешләр кертелмәсә, РСМ җитәкчелегенә дә, ил җитәкчелегенә дә үзем чыгып, хәлне аңлатып бирергә мәҗбүр булачакмын, дип кисәтте һәм калдырылган шәһәрләрне кире кайтарырга да вәгъдә итте. Хәлбуки, МХОдагы борылыш үзен сәясәттә дә сиздерә. Әйтик, Франция лидеры Э.Макрон узган атнада В.Путинны МХОны туктатырга чакырды. С.Лавров әйтүенчә, Россия бүген Украина белән сөйләшүләрдән баш тартмый, әмма ул никадәр күбрәк артка чигерелсә, якларга үзара килешенүе шуның кадәр кыенрак булачак. Ул Киевнең сөйләшү шарты итеп Россия гаскәрләрен Украинадан тулысынча чыгару куелуына зарланды.

Узган атнада җитди вакыйгалар Бөекбританиядә дә булды. Анда премьер-министр вазифасын моңа кадәр тышкы эшләр министры булып торган Лиз Трасс биләде. Королева Елизавета II аңа яңа хөкүмәтне формалаштыру бурычын йөкләде. Яңа премьер-министр Британияне тоткарлый торган проблемаларны хәл итү вакыты җиткәнлеге турында белдерде һәм бөтен дөньяда демократияне якларга вәгъдә итте. Ә ике көн үтүгә, 96 яшьлек королеваның инде бакыйлыкка күчүе, Бөекбританиянең яңа короле итеп Уэльс принцы Чарльз (аңа 73 яшь, ул Карл III исемен алган) билгеләнүе мәгълүм булды.

Фоат УРАЗАЙ.

(Дәвамы. Башы 35 нче санда).

Репрессия афәтен башыннан кичергән Йосыф Ибраһимовның хәрби өлкә белән бәйле баштагы тормыш юлы хәзерге Башкортстанның Авыргазы районына керүче Тукай исемле татар авылында дөньяга аваз салган Якуб Чанышевныкыннан әллә ни аерылып тормый. Туган авылындагы рус-татар мәктәбендә мич ягучы булып торганда үзлегеннән уку-укыту программасын үзләштергән Якуб атлы малай Казанда Татар укытучылар мәктәбендә укый, 1913 елда патша армиясенә хәрби хезмәткә чакырыла. Беренче бөтендөнья сугышында кылган батырлыкларын исәпкә алып, орден белән бүләкләнгән, киләчәге өметле фейерверкерны (өлкән сержант) фронттан Казанга, прапорщиклар мәктәбенә җибәрәләр. Әмма укуын тәмамлаган яшь офицерны Татар иле башкаласында кабынып киткән революцион кутәрелешнең утлы өермәсе бөтереп ала: ул инде кабаттан сугыш кырына ашкынып тормый – яңа хакимият төзүчеләр сафына баса. Пржевальский каласында (хәзерге Кыргызстанның Каракол каласы) сәүдәгәр гаиләсендә туган Йосыф Ихсан улы әүвәл үзләрендәге татар мәктәбендә укый, коммерция училищесында эшмәкәрлек серләренә өйрәнә һәм дөньяның күп илләрен ялмап алган империалистлар сугышына мобилизацияләнә, Ташкент хәрби училищесында кыска сроклы курслар тәмамлап, прапорщик званиесе алып чыга. 1915-1916 елларда подпоручик һәм поручик званиеләренә үрләтелгән Йосыф Ибраһимовның патша армиясендә хезмәт иткән соңгы урыны – 30 нчы Төркестан укчы полкы.

Октябрь инкыйлабыннан соң 2 нче батальон командиры, киләчәге гаять өметле патша офицеры яңа хакимият төзергә алынучылар ягын сайлый: 1918 елда – Төркестан совет республикасының Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы, Оренбург хәрби советының Илецк төркеме штабы башлыгы, Каспий арты хәрби советы штабы әгъзасы. Шул ук елда Ташкентта яшь Төркестан республикасының мәгарифен һәм аның армиясен торгызуга ярдәм йөзеннән РСФСРның Милләтләр буенча халык комиссариаты тарафыннан җибәрелгән миссия кысаларында эшләгәндә дә үзен булдыклы оештыручы буларак таныта. 1919 елда ул инде 1 нче аерым Идел буе Татар укчы бригадасы командиры. Дамир Шәрәфетдиновның “Комбриг Йосыф Ибраһимов” исемле китабында расланганча, Ибраһимов Татбригадада бер ел гына хезмәт итеп өлгерә. Әмма һәр көн саен, һәр сәгать саен революция язмышы сыналган, кыл өстендә торган ул елның мөһимлеген бәяләп бетергесез. Бу чорда ул үз командирлары һәм солдатлары белән бик нык дуслашып өлгерә, әле җитмәсә, 1920 елның 15 мартында үзен Ташкентка чакыру турында боерык алгач, каушап та кала. Чөнки боерыкта аның Төркестан фронтының Реввоенсовет әгъзасы итеп раслануы турында әйтелә. Сүз дә юк, М.Фрунзе һәм В.Куйбышев белән бергә эшләргә чакырулары 25 яшьлек кызыл командирның йөрәгенә сары май булып ята, аның күңелен горурлык хисләре били.

Йосыф Ибраһимовны андый югары дәрәҗәгә билгеләү турындагы карар ике көн алда гына РКП(б)ның Төркестан крае мөселман комитеты, Төркестан Үзәк башкарма комитеты һәм Төркестан фронтының Реввоенсоветы тарафыннан үткәрелгән уртак киңәшмәдә кабул ителә. Реввоенсоветта оператив эш башкарган чагында ул данлыклы Бохара операциясен әзерләүдә катнаша һәм алтын корал белән бүләкләнә. 1920 елның ноябрендә ВКП(б) ҮКнең Төркестан бюросы карары белән Бохара Халык республикасының хәрби нәзире (комиссар) итеп билгеләнгән Й.Ибраһимов яшь республиканың Кызыл Армиясен оештыруга саллы өлеш кертә.

Бу урында, бераз артка чигенеш ясап, кечкенә бер өстәмә кертеп үтү артык булмас. 1919 елның 26 октябрендә Төркестан фронты гаскәрләренә көндерелгән боерык (№49) буенча 1 нче һәм 2 нче аерым Идел буе Татар укчы бригадалары белән аерым Төркестан бригадасын берләштерү нәтиҗәсендә 2 нче Мөселман укчы дивизиясе оеша. Аның беренче башлыгы итеп Й.Ибраһимов билгеләнә. Фронт командующие Фрунзенең чираттагы боерыклары белән (№76 һәм №6) дивизия 1919 елның 24 ноябрендә – 2 нче Төркестан, ә 1920 елның 25 гыйнварыннан кызыл коммунарларның 2 нче Төркестан укчы дивизияләре итеп үзгәртелә. Димәк, фәкать шуннан соң гына Йосыф Ихсан улы Реввоенсовет әгъзасы итеп раслана.

Урта Азиядә совет хакимияте урнаштыру яу кырында гына бармый, үзара эчке көрәш, тарткалаш барлык өлкәләрне дә чолгап ала һәм катлаулы хәл-вакыйгалар белән вәзгыять бик тиз үзгәреп тора. Чынлыкта, Йосыф Ибраһимов Бохара республикасы хәрби комиссары итеп, ул вазифадагы күренекле татар большевигы, кызыл командир Баһаветдин (Барый) Шиһабетдинов басмачылар кулыннан һәлак булгач билгеләнә. Бу вазифага Төркестан АССРы Советларының 1919 елның сентябрендә үткән VIII съездында шулай ук М.Фрунзе тәкъдиме белән расланган Шиһабетдинов чыгышы белән Рязань өлкәсенә керүче данлыклы Әҗе авылыннан, 1919 елның декабреннән – Семиреченский (хәзерге Казахстанның Җиде су өлкәсе) өлкә революцион комитеты рәисе һәм өлкә хәрби комиссары, 1920 елның февраленнән өлкә хәрби комиссары вазифаларын башкара. Шулай ук Алма-Атадагы бер урамга аның исеме бирелгәнен шәрехләп үтү дә артык тоелмас. Бер җәһәттән Йосыф Ибраһимовның, аның турында язучылар тарафыннан бәян ителмәүче тагын бер вазифасын искәртү урынлы. Тарих фәннәре докторы Ф.Касыймов белән фәлсәфә фәннәре кандидаты Б.Эргашов тарафыннан “Родина” журналында нәшер ителгән “Бохара революциясе исемле мәкаләдә ул турыда да сүз бар:

“2 сентябрьдә (1920 ел) гаскәрләр Иске Бохараны яулап алды. Әмир илнең көнчыгышына качты, ә хакимият таҗик халкының күренекле шагыйре Әхмәдҗан Абусәидов җитәкчелегендәге Гомумбохара (Үзәк) Революцион Комитеты карамагына күчте. Яңа оешкан хөкүмәт – Халык нәзирләре советын, нигездә, яшь бохарачылар (младобухарцы) тәшкил итте: рәис һәм тышкы эшләр нәзире – Ф.Хоҗаев, гадәттән тыш комиссия рәисе (4 сентябрьдә, башкалада гадәттән тыш хәл кертелгәннән соң оеша) – Й.Ибраһимов, юстиция нәзире – М.Борханов, хәрби эшләр нәзире – Б.Шиһабетдинов”.

● Йосыф Ибраһимов.

Бохара халык совет республикасы дошманнарының тырышлыгы белән 1921 елның язында Йосыф Ибраһимовны хәрби нәзир вазифасыннан азат итәләр. Тарихчы Д.Шәрәфетдинов бу вакыйга уңаеннан тагын бер милләт баласы, чыгышы белән Рязань өлкәсенең Яубаш (Болотцы) авылыннан чыккан, Бөек Ватан сугышында 29 нчы моторлашкан дивизия белән командалык иткән генерал-майор Ибраһим Бикҗановның Ташкентта “Совет Төркестаны өчен” исеме белән төрле шәхесләренең истәлекләре тупланган китаптагы (1963, 487 бит) хатирәләреннән шактый кызыклы өземтә китерә: “1921 елның язында, ул чакта безнең өчен аңлашылмаган сәбәпләр аркасында, бөтен көчен һәм белемен армияне оештыруга биргән хәрби нәзир Й.Ибраһимовны вазифасыннан алдылар. Нәзир итеп, аңарчы армиядә хезмәт итмәгән, хәрби эшкә бөтенләй катнашы булмаган Нәзировны куйдылар. Без бу җитәкчедән берниндәи дә яхшылык көтмәдек...” .

Әле 1920 елның җәеннән үк Төркестан компартиясенең Үзәк комитеты әгъзасы булып торган Йосыф Ибраһимов 1921 елның язынан Төркестан АССРы эчке эшләр халык комиссарының урынбасары вазифасына билгеләнә. Әмма бу вазифада да озаклап эшләргә туры килми, көзгә кергүгә аны, татар телендә сөйләшә белгән һәм безнең милләттәшләргә карата аерым

дәһшәте

● Нигъмәтулла Еникеев.

бер ихтирам, хөрмәт белән караган М.Фрунзе Тифлискә, үз карамагына чакыртып ала. Илдә гражданнар сугышы тәмамланырга бер ел чамасы калып барган мәл. Дөньяда яшь совет дәүләтен танучы илләр арта бара, араларында иң өлгере – бөек реформатор Ататөрек хакимияте үз кулларына алган Төркия иле. 1921 елның мартында ук Төркия белән РСФСР арасында дуслык һәм тугандашлык турындагы килешүгә кул куела. Чиратта – Украина. Төрек ягы белән сөйләшүләр үткәрү өчен Украина Үзәк башкарма комитеты әгъзасы, Украинадагы һәм Кырымдагы кызыл гаскәрләрнең Башкомандующие М.Фрунзе җитәкчелегендәге дәүләт делегациясе оеша. Нәкъ менә Фрунзе таләбе белән данлыклы комбриг Йосыф Ихсан улы шул махсус миссия составына кертелә.

1922 елның ноябрендә, составындагы исем-фамилияләре үзгәртелгән миссия әгъзалары юлга кузгала: әүвәл итальян пароходында Батумидан Трапезундка киләләр, аннары Синопка барып җитәләр. Аннан соң Анкарага чаклы араны атларда үтү өчен 12 көн вакыт үтә. Төрек хөкүмәте ул араны узган чакта, җирле халык белән очрашу, аралашу өчен зур мөмкинлекләр тудыра. Делегация Төркиядә 1921 елның 26 ноябреннән 1921 елның 16 гыйнварына чаклы була. Шуның нәтиҗәсе буларак, 2 гыйнварда М.Фрунзе белән Ататөрек Украина белән Төркия арасындагы дуслык һәм тугандашлык турындагы килешүне имзалый, делегация исә гыйнвар ахырларында илгә кайтып җитә. Шундый мөһим дипломатик миссияне үтәп кайтканнан соң Йосыф Ибраһимов Ташкентка әйләнеп кайта, бик җаваплы урыннар били. Әмма иң беренчеләрдән булып репрессияләр афәтенә эләгә, ягъни үзе көрәшеп алышкан яңа хакимият башында торучылар өчен ят кешегә әйләнә. Кыргызстанның авыл хуҗалыгы банкы управляющие булып эшләгәндә "халык хуҗалыгы байлыгын сарыф иткәне өчен" гаепләнә һәм вазифасыннан алынып, партиядән чыгарыла. 7 айдан кабат ВКП(б) сафларына кайтаралар, әмма бераздан тагын партиядән куалар. Якуб Чанышев үз истәлекләрендә Кыргыз авыл хуҗалыгы банкы идарәчесе вазифасыннан алынган һәм хөкемгә тартылган сәүдәгәр малае Йосыф Ихсан улын "Солтангалиев тарафдары" буларак, басмачыларга ярдәм иткәне өчен дә" нигезсез гаепләп чыгулары турында яза.

Бөек Ватан сугышына кадәр Йосыф Ибраһимов Ташкент дәүләт университетында һәм Сәмарканд укытучылар педагогика институтында хәрби җитәкче булып эшли. Әмма 1930 елларда да, "Солтангалиев тарафдары" һәм "Рыскулов тарафдары" ярлыклары тагылган милләт баласын туктаусыз тинтерәтүләр дәвам итә. Данлыклы комбригның кызы, тарих фәннәре докторы Анел Ибраһимованың КПССның Татар өлкә комитеты архивына язган хатында (ПАТО, ф. 30, оп.3, д. 382 а.) нәкъ шул расланa: "Кызганычка, мин сезгә әтием турында бер генә материал да җибәрә алмыйм. Әти белән бәйле булган бөтен нәрсәләрне без биреп бетердек, гомумән, 1937-1938 елларда аларның барысын да диярлек юк иттеләр. Хәтта анаң алтын коралы да сакланып калмады".

Тарихчы Дамир Шәрәфетдинов үз хезмәтендә архивта сакланучы (ПАТО, ф. 30, оп. 3, д.309, л. 55) бер мөһим документтан китергән өземтәдә Сталин режимының татарларга карата нинди явыз позициядә торуы ачык тасвирлана: "...бригаданың элекке сәяси бүлеге башлыгы Н.С.Еникеев үзенең Бериягә язган шикаятендә... хәтта Татар бригадасында хезмәт итүнең тикшеренүчеләр тарафыннан контрреволюцион эшчәнлек буларак бәяләнүен ассызыклый".

Әлбәттә, Нигъмәтулла Еникеевның кискен яңгыраган гаепләү сүзләрендә хаклык зур. Мондый фикер сөреше белән тарихчы Д.Шәрәфетдинов та килешә: "1 нче аерым Идел буе Татар бригадасының комиссары, танылган татар язучысы Шамил Усманов 1918 елдан ук "революционер-теоретик маскасына яшеренгән Солтангалиев тарафдары", "икейөзле милләтче", "контрреволюционер" дип игълан ителә. Ул НКВД төрмәсендә тикшерү вакытында җәзалаганда йөрәгенә паралич сугудан һәлак була.

Йосыф Ихсан улының хәрби көрәштәшләре дә репрессия тегермәненә эләгә: Искәндәр Тальковский, Хөсәен Мәүлитов, Галиулла Касыймов һәм татарлар арасыннан беренче совет дипломаты – Иранда генераль консул, Согыд Гарәбстанында һәм Йәмәндә вәкаләтле вәкил булып торган Кәрим Хәкимов, Төркиядә хәрби атташе ярдәмчесе һәм Иранда хәрби атташе булган Һади Маликов һ.б."

Башкортстандагы Яңа Каргалы авылында туып-үскән һәм бригада комиссары званиесендә хәрби хезмәттән китәргә мәҗбүр булган милләт баласы Нигъмәтулла Еникеев мактаулы тормыш юлы үтә, шул ук вакытта фаҗигале язмышка да дучар була. Яңа хакимият төзүчеләр ягына баскан патша армиясенең өлкән унтер-офицеры Еникеев бер елдан артыграк 1 нче Татар Идел буе укчы бригадасының сәяси бүлеген җитәкли, Бохара республикасының хәрби нәзарәтендә сәяси идарә башлыгы вазифасын башкара, Мәскәүдәге И.Сталин исемен йөртүче Көнчыгыш хезмәтчәннәренең Коммунистик университетында лектор булып эшли. Аннары Татар иле башкаласы Казанга әйләнеп кайта һәм 1923-1926 елларда – Үзәк мөселман хәрби-сәяси мәктәбендә, 1926-1935 елларда ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты исемен йөртүче 6 нчы Берләштерелгән Татар-башкорт хәрби мәктәбендә комиссар һәм башлык вазифаларында хезмәтен дәвам иттерә. ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы икееллык марксизм-ленинизм курсларын тәмамлагач, М.Фрунзе исемендәге Омск хәрби училищесының сәяси бүлегенә комиссар һәм башлык итеп билгеләнә. 1937 елның 22 декабреннән 1939 елның 4 декабренә чаклы НКВДның канлы подвалларында иза чигә. Идел буе хәрби округы суды тарафыннан аклана, әмма кыйный-кыйный сорау алулар вакытында сәламәтлеге тәмам какшау сәбәпле хәрби хезмәттән азат ителә. Үзбәкстанда яши, төрле административ эшләрдә җаваплы вазифалар башкара, Кызыл Байрак һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры Нигъмәтулла Еникеев 1971 елда вафат була, бакыйлыкка күчкән урыны – Үзбәкстан ССРның Фиргānә каласы.

Бер гаепсезгә язмышы сындырылган Йосыф Ибраһимов исә Бөек Ватан сугышы башлану белән яу кырына китәргә теләк белдерә. Дүртенче дистәсенең икенче яртысын ваклый башлаган, шактый өлкән яшьтәге офицерны штабы Ташкентта урнашкан запастагы полкның батальон командиры вазифасына куялар, 1942 елдан фронтта: әүвәл – 213 нче укчы дивизия составындагы 702 нче укчы полкның штаб башлыгы, аннары – 95 нче һәм 87 нче аерым укчы бригадаларына керүче частьләр белән командалык итә. Сугыш тәмамланыр алдыннан – 1 нче Белоруссия фронты составындагы 356 нчы Кызыл байраклы Суворов орденлы укчы дивизиягә турыдан-туры буйсынуда булган 183 нче Кызыл Йолдыз орденлы аерым сапер батальонында командир ярдәмчесе. 1945 елның 7 маенда СССР Югары Советы Президиумы исеменнән үз яугирләрен бүләкләү турында чыккан һәм дивизия командиры генерал-майор Михаил Макаров белән штаб башлыгы подполковник Сергей Семидумов имзалаган боерыкта (№120/н) Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүчеләр арасында капитан Йосыф Ибраһимов та бар. Шул орденнан тыш, "Берлинны алган өчен", "Варшаваны азат иткән өчен" һәм "Бөек Ватан сугышында Алманияне җиңгән өчен" медальләре белән бүләкләнгән Йосыф Ибраһимов 1946 елның гыйнвар ае тәмамланып килгәндә демобилизацияләнә, 1961 елда вафат була.

(Дәвамы киләсе санда).

Рәис ЗАРИПОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

17 сентябрь (шимбә). ***Сәфәр аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 20.17 сәгатьтә калка, 15.19 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.38 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Канны чистарту

1 стакан кайнар суга 1 чәй кашыгы вак кына туралган кычыткан салып, 45 минут төнәтәләр. Сөзеп, көненә 2 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр аш кашыгы эчәләр. Дәва курсы – 1 ай.

18 сентябрь (якшәмбе). ***Сәфәр аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,20.58 сәгатьтә калка, 16.08 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.33сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Нарат җиләге

Артритны нарат җиләге яфрагы кайнатмасы шәп дәвалый, чөнки әлеге үсемлек организмнан артык тозны чыгарырга сәләтле. 2 чәй кашыгы яфракны 1 стакан кайнар суга салып, сүрән утта 15 минут пешерәләр. Суынгач, сөзәләр һәм тәүлек дәвамында әз-әзләп эчеп бетерәләр.

19 сентябрь (дүшәмбе). ***Сәфәр аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,21.54 сәгатьтә калка, 16.42 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.29 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Стоматиттан дәва

Стоматит балаларны да, өлкәннәрне дә интектерә. Аңардан котылу юлы исә бик гади: мамык тампонны сырганак маена манып, авыз эченә сөртергә кирәк. Тәүлегенә 3-6 тапкыр шулай дәвалаңганда, 1-2 көннән соң хәл җиңеләя, 1 атнадан исә җәрәхәтләр тулысынча төзәлә.

20 сентябрь (сишәмбе). ***Сәфәр аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,23.03 сәгатьтә калка, 16.53 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.24 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Сөтле сабын

Чуан чыгып интектергәндә, болай дәвалаunion: Кер сабынын кырып, өстенә шуңардан ике тапкыр күбрәк сөт салалар, болгата-болгата сүрән утта 1 сәгать кайнаталар. Каймак кебек куерган катнашманы чуанга сылап, бинт белән бәйлиләр. Көн саен алыштыралар. Уколдан соң шешкән урыннарга исә кефирдан компресс куярга кирәк.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама кырын

21 сентябрь (чәршәмбе). ***Сәфәр аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Арыслан йолдызлыгында, 17.05 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.19 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Бал иммунитетны ныгыта

Иммунитетны әкренләп ныгыту өчен, баллы су эчәргә киңәш итәләр. 1 стакан салкынча чиста суга 1 чәй кашыгы бал салып болгатырга һәм иртәнге ашка чирек сәгать кала эчәргә кирәк. 30 процентлы бал эремәсе барлыкка килә, аның составы кан плазмасына бик охшаганга, файдалы компонентлары тизрәк һәм яхшырак үзләштерелә. Балга дарчин кушып ашау да иммунитетны ныгыта.

22 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Сәфәр аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 0.21сәгатьтә калка, 17.21 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.15 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Имбир ютәлне баса

1 әр чәй кашыгы лимон һәм кыргычта кырылган имбир согын кушып, 30 минут төнәтәләр, ярты стакан кайнар су өстәп, капкач каплыйлар, бераз суынгач, 1 чәй кашыгы бал кушып, һәр ярты сәгать саен 1 әр чәй кашыгы кабалар. 1 стакан сөтне кайнатып чыгарып, 1 чәй кашыгы коры имбир порошогы салып болгаталар да, бераз суынгач, бал һәм куркум кушып, йоклар алдыннан эчәләр, бу бигрәк тә юеш ютәл интектергәндә файдалы. 1 әр чәй кашыгы имбир порошогы һәм канәфер кушып, яшел чәй пешереп эчү дә ютәлне баса. Кайнап торган суга чистартып туралган имбир телемнәре салып, тәелгән кара борыч өстиләр дә, сүрән утта пешерәләр, 10 минуттан соң кара чәй кушып, уттан алалар, бераз өстен томалап тоткач, сөзеп, лимон яки сөт кушып эчәләр. Кайнап торган суга кырылган имбир салып, 20 минут пешерәләр, сүндергәч, лимон согы өстиләр, бал белән эчәләр.

23 сентябрь (җомга). ***Сәфәр аеның 27 нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 1.41 сәгатьтә калка, 17.33 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.10 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Кабак вареньесы

1 кг кабакка – 1 кг шикәр, 1 лимон (яки әфлисун) кирәк. Чистартылган кабакны вак шакмаклап турыйлар, шикәр сибеп, 4-5 сәгать тоталар. Сүрән утта кайнатып чыгарып, 20-30 минут пешерәләр. Лимонны юып, цедрасын кабак өстенә кыралар, ак кабыгыннан чистарталар, иттарткычтан чыгаралар һәм әзер вареньега кушалар. Суытып, банкаларга тутыралар, суыткычта саклыйлар.

Әлфиянең урак өсте

Быел алтындай иген басулары янынннан узып киткәндә, күңел чиксез шатлык кичерә: игенченең түккән хезмәтен газиз җиребез мул уңыш белән бәяләде. Актаныш кызы Әлфия Ситдыйкованың әле генә Татарстан китап нәшрияты чыгарган “Таш тамыры” китабын укыганда, мин иген басуларына карагандай куандым.

Үзенең 65 яшьлек юбилеена ул әдәбият багында илһамланып эшләп керде. Моңа кадәр укучылар күңеленә шигырь, поэма-сонетлар рәвешендә чәчелгән орлыклардан үсеп чыккан эпик әсәрләрне күрү дә насыйп булды. Ә.Ситдыйкова әллә кайлардан тема, герой, вакыйгалар эзләп йөрми. Аның тормыш тәҗрибәсе искиткеч бай. Авылның үткәне һәм бүгенгесе, кешеләренең кабатланмас язмышы шагыйрәнең күңелен сызландырып та, горурландырып та тора һәм күпчелек әсәрләрәнә, гүя аның ихтыярыннан тыш, ирексездән бәреп керә кебек. Шуңа Әлфиянең әдәби әсәрләре документаль текст кебек ышандыра яки чын документаль язмалары (мәсәлән, әлеге китаптагы “Таш тамыры”) әдәби-нәфис бәяндәй тәэсир итә.

Язучының төп геройлары – гади хатын-кызлар. Алар алдына тарихи чынбарлык гаҗәеп афәтле каршылыклар, зур сынаулар куя. Шуларны җиңеп чыгу өчен күркәм затларыбыз вөҗданлылык, игелеклек һәм гайре табигый рухи ныклык үрнәкләре күрсәтә. Алар арасында чын батыр булып Ана образы күтәрелә. Ә.Ситдыйкова әлеге китаптагы өч әсәрдә дөньяны тотучы бөек вә серле мәхәббәт чыганагы булган Аналарга мәдхия укый, алар алдында баш ия. (Аның иҗатын тулаем хатын-кызга, аналарга дан җырлау дип бәяләсәк тә дөрестер, дип уйлыйм.)

“Диңгез суы тозлы ул” дигән романда Таулы авылының пакь күңелле, иманлы дүрт ана язмышы ачып бирелә. Аларның һәрберсенең тормышы зур романга тиң. Автор вакыт-вакыт чәчмә сурәтләүдән шигырь юлларына күчә-күчә, поэтик сүз егәрен оста файдаланып, вакыйгаларны метафора дәрәҗәсендә тыгызлауга ирешә.

Беренче героиня – үз язмышын үзе язган Мәбрүрә исемле кыз. Алты баласы белән ятим калган сугыш ветераны Кираметдинга сабыйларны кызганып кияүгә чыга ул. Уртак балалары да туып, ун елга якын гына бергә яшәгән ире вафат була.

– Бәрәч! Балакаем, нишләп тордың? Бар, урыныңа ят, йокла, бәбкәем.

– Әнкәй... Син безне детдомга бирмә, яме!

– Нинди сүз бу, балакаем?!

– Мәктәптә малайлар әйтәләр: “Уку елы беткәч, сезне детдомга озаталар!” – диләр.

– Миндә артык балалар юк. Барыгыз да үземнеке генә.

– Ә без сине беркемгә дә алыштырмыйбыз. Безнең әнкәй син генә. Без сине мәңге ташламабыз, әнкәй!

Ике як та сүзендә тора. Олы йөрәкле Мәбрүрәнең 90 яшенә җиде бала, киленнәр, оныклар кайта, авылдашлары җыела.

“Мирас булып калган бар байлыкны
Таркатмыйча саклап яши Ана.
Мәхәббәткә тугры калу белән
Үз-үзенә аумас һәйкәл сала.”

Гөлниса ире Сафуанны сугышка озата. Ике яшьлек баласы үлә. Ә ире бүтән кызга өйләнеп кайта, алар Гөлнисага күрше генә булып яши башлый. Ул иренең шул хатыннан туган балаларын сөеп юана, беркемгә дә ачу сакламый, сугыш афәтен гаепли. Сафуан үлгәннән соң, акылын җуеп, бакыйлыкка күчә. Аны Сафуан кабере белән янәшә җирлиләр...

Автор аналар язмышын төрле яклап ача. Әйтик, Әдибә, ире хәрби врач булу сәбәпле, аның белән бергә Украинада, Германиядә төрле шәһәрләрдә яшәргә дучар итәлә. Ул үзен татар дигән милләтнең гореф-гадәтләрен, телен саклаучы, нык ихтыярлы унган шәхес итеп таныта. Башка милләт кешеләренә хөрмәт белән каравын, дустанә мөнәсәбәтен көндәлек яшәү рәвеше, җылы карашы белән раслый. Шуның бәрабәренә үзе дә, гаиләсе дә олы абруй казана. Туксанынчы елларда ике баласы белән ул туган авылы Таулыга кайта. Уларының табиб булуларын, оныкларның үсүләрен күреп куана.

Бу авылның тагын бер данлыклы Анасы Саниягә сокланмый мөмкин түгел. Ул үзенең өч баласы өстенә уноч бала алып тәрбияли. Татарстан Президенты М.Шәймиев Казанның иң затлы тантаналар залында Саниягә машина ачкычы тапшыра. Уналты баланы тәрбияләү мәшәкатьләрен күз алдына китерү дә кыен. Бу бит мәктәпнең бер сыйныфына тиң! Мондый аналарны чын Ил Анасы дияргә мөмкин!

“Сабыен баккан ананың карашы тулы наз, – дип яза автор. – Ягымлылык, нәзакәтлелек, сөю тулы җылы караштан сабый күңеле генә түгел, бөтен дөнья җылынгандай була. Тирә-якта гөлләр чәчәк ата, көмеш чишмәләр күзен ачып, челтерәп ага башлый, сандугачлар яңа җыр суза... Ана күңеле тирән диңгез сыман... барысы да сыя... Әмма карап торышка никадәр гүзәл тоелса да, диңгез суы тозлы ул. Тормыш үзе шулай түгелмени?!”

Яшьлек романтикасы белән сугарылган “Дөнья тәгәрмәче” повесте да хатын-кыз язмышына багышланган. Бу әсәр психологик тирәнлеге, фәлсәфи уйлануларга, җанлы вакыйгаларга байлыгы, сюжет-композицион бөтенлеге белән аерылып тора. Повесть авыл мәктәбеннән тыш берни дә күрмәгән яшь кызның КамАЗ заводына эшкә урнашып, шушы гигантның коточкыч зур тегермән ташларыдай күз иярмәс тизлектә корыч чыңнар таратып әйләнүче производство тормышында уалуы, әвәләнүе белән башлана. Ул эшендә дә, шәхси тормышында да ялгыша, аларны төзәтә һәм яңа дәрт белән яшәргә керешә. Повестьның төп герое Мәдинәгә кайнар мәхәббәтне татырга, ялгызлык ачысын кичерергә туры килә. Ләкин ул сынмый, сыгылмый, балаларына чын ана булып кала. Шул ук вакытта шигъри аһәңле, ялгызлыгын җиңеп, әдәбиятта үз урынын таба. Бу героиня Әлфия Ситдыйкованың үзе түгелме соң инде? Шулай, әлбәттә! Әллә каян прототиплар эзләмәгез. Барысы да дөрес. Китапта язылган барлык сынаулар һәрберегезгә дә килергә мөмкин, язмыш аяусыз, аларны җиңәргә әзер булыгыз, дип кисәтә кебек автор.

Фоат САДРИЕВ.

Хатлар яздым утырып

Оешмасы бар, вәкаләте юк

Җитәкчеләрнең чыгышларын тыңлаганда, милләтара дуслыкта, татулыкта яшибез Татарстанда, дигән сүзләрен ишетеп торабыз. Илдә яшәүче милләтләр арасында тигез хокуклылык булмаганда, аңы булган халыкны андый сүзләр белән генә ышандырып булмыйдыр ул. Илдә бер генә тел калдыру белән хыялланып, башкаларның балаларына мәктәпләрдә үз ана телендә укулар тыелуы милләтара татулык булсын өчен түгел, киресенчә, дошманлык тусын өчен эшләнә кебек түгелме?

Элеккеге еллардагы кебек, мәктәпләрдә балаларга татар теле укытылганда, татар телле балалар бакчалары эшләп торганда, хәзерге шикелле телне саклау стратегиясе һәм комиссияләре булмаганда, телебезнең сакланып калуына өметләнеп була иде кебек.

Хәзерге вакытта эшкә ашмастай, кеше башын катырыр өчен уйлап чыгарылган телне саклау стратегиясе дигәннәре турында сүзләр тынып калды. Бу эшнең хәйләкәрлек белән, вакыт үткәреп, телне саклап калуда бернинди катнашы булмавы турында язып торалар иде, шулай булып чыкты да. Бу эш белән шөгыльләнүче җитәкчеләрнең күпме вакытлары һәм язылган кәгазьләренең файдасызга исраф ителүен уйлап карасак, аптырап, исең китәрлек.

Тел саклап калу, үстерү өчен дигән булып, төрле чаралар үткәргән конгрессны һәм телне саклау комиссиясен мактап буламы соң? Юк, дип саныйм. Тел саклансын өчен, балалар бакчасыннан башлап, мәктәпләрдә татар теле дәресләре кирәгенчә итеп һәм мәҗбүри рәвештә алып барылырга тиеш. Телне саклау комиссиясенә мәктәпләргә элеккеге укыту системасын кайтару вәкаләте аңа бирелмәгән.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Борынгылар әйткән сүзләр

(Мәкальләр һәм әйтемнәр)

Хуҗи МӘХМҮТОВ

ТӘМУГ КИСӘВЕ

Дини тәгълимат буенча, Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы бәндәләр тәмугта ут белән газап кылыначак, ягъни утын (кисәү) сыйфатында тәмугта яначак. Аеруча зур гөнаһ ияләре мәңгелек януга хөкем ителә, димәк, андыйлар «мәңгелек тәмуг кисәве» була.

Каюм Насыйриның «Әбугалисина» кыйссасында Аллаһы Тәгаләгә иман китермәүче, гаять азгын һәм бозык сихерче Дакъянус патша сурәтләнә. Әбугалисина аңа ачуланып болай дип мөрәҗәгать итә:

«-И мәлгунь, мәңгелек тәмуг кисәве, миннән ни морадың бар?» (Сайланма әсәрләр: ике томда. -Казан, 1974).

Яки:

«[Гыйззәт хәзрәт:] Хәлләребез яман, кем, Иргали улым. Гөнаһларыбыз баштан ашкан. Шул гөнаһларыбыз өчен Хода каршында мәңгелек тәмуг кисәүләре булу ихтималыбызны онытабыз (Мәхмүт Хәсәнов. Язгы ажаган).

Бу әйтелмә телебездә «Җәһәннәм кисәве», «Тәмуг утыны», «Җәһәннәм утыны» вариантларында да очрый. Алар Коръәндәге «лиҗәһәннәмә хатаба» («җәһәннәм утыны») тәгъбиреннән таралган булырга мөмкин. Андагы «Җиннун» («Җеннәр») сүрәсенең 14, 15 аятьләрендә болай диелә:

«Чынлап та безнең арада Аллаһыга буйсынганнар бар, һәм безнең арада юлдан язганнар бар; кем буйсынган – алар туры юлда, ә юлдан язганнар исә – алар җәһәннәм утыны».

«Тәмуг кисәве» әйтелмәсе сүгү, тиргәү, ачулану өчен генә түгел, бәлки вәгазь, үгет-нәсыйхәт йөзеннән дә кулланыла. Бу икенче очракта кешене, гөнаһлы эшләрдән тыю максатында, «тәмуг кисәве була күрмә» дип кисәтәләр. Менә Г.Тукайның «Исемдә калганнар» әсәреннән бер мисал. (Кечкенә Апушны, Сәгъди абзый гаиләсеннән аерып, Кырлайдан Уральскига алып киту мизгелләре):

«Әти-әни, бичаралар, һәр икесе, егълаган хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың», - дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек» (Әсәрләр: дүрт томда. -Казан, 1977).

Ә монысы Габделхак хәзрәт Самат вәгазеннән бер өзек:

«Газиз кардәшләрем! Юк-бар нәрсәләргә ияреп һәлак булмагыз. Коръән аятьләрен ихтирам кылып, ул өйрәткәнчә гамәл кылыйк. Аллаһының каргышына дучар булып, җәһәннәм кисәве булмыйк» (Шәһри Казан).

ТИРӘК БАШЫН ЮГАРЫ КҮТӘРГӘН ӨЧЕН ҖИМЕШТӘН КОРЫ КАЛГАН

Мәкаль җыентыкларында еш очрый торган бу гыйбарәнең килеп чыгышы мондый бер кинаяле хикәят белән бәйләнгән:

«Иң тәү башта тирәк агачы да башка җимеш агачлары шикелле җимеш бирәсе булган, буйга-сынга да алар белән бер чамада гына үскән, ди. Тик ул тиктомалдан үзалдына һаваланып китеп, минсенергә тотынган: «Мин башкалар ише генә түгел, мин алар белән тиң түгел!» - дип, лыбыр-лыбыр сөйләнергә керешкән... Менә шуннан бер дә хәтәр эреләнеп, борынын тиешеннән артык күккә чөеп, тотынган, ди, үсәргә. Шулай киерелә-сузыла торгач, һәммә җимеш агачларыннан да биегрәк, калкурак булып киткән, ди.

Тик аның болай үз дәрәҗәсеннән чамасыз артык үсүе үзенә файдалы булып чыкмаган, ди. Аның шулай: «Мин минме икән, мин кем икән?!» – дип үзенә шаккатып торган чагында гына, агачларга җимеш өләшү башланган, ди. Алмагач үзенең алмасын, чикләвек агачы үзенең чикләвеген, шомырт, балан, миләшләр дә – бары да, бары да үз җимешләрен алып җимешләнеп беткәннәр. Тик үзенә үзе исе киткән тирәкнең генә моны күрергә вакыты булмаган, башын-борынын югары күтәрү аркасында, җимеш өләшкәндә коры торып калган, имеш, ди» (Балалар фольклоры. Җыеп төзүче Нәкый Исәнбәт. – Казан, 1984).

Аңлашылса кирәк, китерелгән хикәятә, аның сөземтәсен тәшкил иткән гыйбарә дә үзен башкалардан өстен итеп күрсәтергә маташкан кешеләрне гаепләү, кисәтү, аларга үгет-нәсыйхәт бирү максатына хезмәт итәләр. Гомумән, бу тема безнең татар мәкальләрендә катгый-кискен төстә куела:

Үзен-үзе мактаган — агач атка атланган.

Эрелек артыннан хурлык кыдырып йөрер.

Югары очкан түбән кунар.

Борынын күтәргән пычракка капланган.

Туң тимергә балга (зур чүкеч) бар,

Минсенгәнгә Алла бар.

Тәкәббердән Тәңре бизгән.

Тәкәбберга Ходай карышкан һ. б.

Игътибар иткәнсездер: кайбер мәкальләрдә кисәтү Алла (Тәңре, Ходай) исеме белән бәйләп ясала. Бу һич тә очраклы түгел, чөнки ислам әхлагы буенча тәкәбберлек – кешедәге иң нык гаепләнә торган сыйфатларның берсе. Моны пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам хәдисләре дә даимән искә төшереп торалар:

«...Үзендә бер олуглык хис итеп, тәкәбберлек күрсәткән кеше - Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең ачуына дучар булачак кеше» (Гариф Бик. Мең дә бер хәдис шәрехе).

«Тәкәббер вә һавалы булудан бик саклан. Аллаһы Тәгалә тәкәбберлекне сөймидер» (Ризаэтдин бине Фәхретдин. Җәвәмигуль Кәлим шәрхе).

«Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә өч төрле кеше белән шәфкатьле сөйләшмәс: биргән сәдакасы белән миннәт итүче (кылган яхшылыкны гел-гел искә төшереп торучы); комачын (товарын) ялган ант белән үткәрүче; тәкәбберлек йөзеннән киемен сөйрәтеп йөрүче» (шунда ук. – 213б.).

Шагыйрь һәм дин галиме белгече Габдерәхим Утыз Имәни үзенең дидактик әсәрләрендә ислам риваятьләренә, пәйгамбәр хәдисләренә киң таяна, шул җөмләдән ул тәкәбберлеге өчен җимештән мәхрүм ителгән тирәк мотивына да мөрәҗәгать итә. Тикшерелә торган гыйбарәнең шагыйрь тарафыннан афористик калыпка салынган «Тирәкдик син, коры калма кирәкдин» дигән варианты да бар (Шигырьләр, поэмалар / басмага әзерләүче Әнвәр Шәрипов.)

ТӨТЕНСЕЗ (КАЙТМАС) АВЫЛ

Телдәге борынгы табу күренешенә, ягъни шомлы, хәвефле саналган нәрсәләрнең исемнәрен турыдан-туры атамыйча, аларны читләтеп, башка сүзләр аркылы белдерүгә нигезләнгән сакраль әйтелмә. «Ләһҗәи татари» сүзлегендә Каюм Насыйри XIX йөздә татарларның «каберлек» диясе урынга «каенлык», «каенсар», «төтенсез авыл» кебек исемнәр кулланулары турында хәбәр итә. Бу күренеш фольклорда да чагылыш тапкан. Әйтик, зират турындагы табышмакта:

«Авылы бар, төтене юк,
Әтәч кычкырмый,
Халык тормый».

Тәгъбир нәфис әдәбият әсәрләрендә дә еш очрый:

«Сорау алучылар Куян солдатка мондый бер сорау бирделәр:

– Ул үлгән бит инде. Син нәрсәгә аңа хат язып ятасың. Төтенсез авылга хат йөрми булыр бит?

– Үлгән булса, – дип Куян солдат елап ук җибәрде, – мин дә бу көнгә калмаган булыр идем. Андый тәрбиядә торган кеше тиз генә үләмени?..» (Гомәр Толымбай. Хикәяләр. Повестьлар).

«Сез беләсез инде, ачлык белән тиф хастасы минем анамны да «төтенсез авылга» алып киткән. Кайттым, әни юк» (Гомәр Бәширов. Гыйбрәт).

«Ул инде былтыр ук кайтмас авылга киткән» (Нәкый Исәнбәт. Татар теленең фразеологик сүзлеге).

ТАШ ӨСТЕНДӘ ТАШ КАЛМАУ

Бу тәгъбир «Инҗил»дә Гайсә Мәсих сүзләре итеп китерелә.

«Гайсә [Иерусалимдагы] Аллаһы Йортыннан чыгып барганда, шәкертләренең берсе Аңа әйтте:

– Остаз! Кара әле, нинди зур ташлар, нинди матур биналар.

– Син бу зур биналарны күреп таң калдыңмы? – диде Гайсә. – Монда таш өстендә таш калмаячак, барысы да җимереләчәк» (Марк, 13: 1-2).

Гәрчә «Инҗил» (яки аның аерым китаплары) XIX йөз азагы -XX йөз башында ук татарчага тәрҗемәдә 8 мәртәбә басылып чыкса да, бу әйтелмә безгә рус әдәби телендәге «Камня на камне не оставить» дигәнне калькалаштырып алынган булырга тиеш. Мәгънәсе «Инҗил»дәгечә сакланган: берәр нәрсәне нигезенә чаклы җимереп бетерү. Сүз аерым бина-корылма гына түгел, бәлки зур-зур калалар, хәтта илләр, дәүләтләр турында да барырга мөмкин:

«Сәхилә. Менә мин Бики байга кереп әйтим әле үзеңне, йортың урынында таш өстендә таш калмас» (Нәкый Исәнбәт. Сайланма әсәрләр.– Казан, 1968. –Т. 2).

Шушы ук автордан икенче бер мисал (Татар халык табышмаклары. – Казан, 1970):

«Борынгы зур сәүдә юлы булган Идел-Чулман елгасын кулга төшерү өчен урта гасырларда өзлексез сугышлар барган. Шунда дәүләт корган Болгар, Алтын Урда, Казан җирләре шул сугыш зонасы булганга, шәһәрләре җимерелеп, таш өстендә таш калмаган».

«Батырҗан (җырлый):
Язгы ташкын ярсыгандай
Ярсый йөрәк, уйларым.
Ярсып күңелем көтә минем,
Көтә җиңү туйларын.
Юллар буйлап, кылыч болгап
Шәһәрләргә җитәргә,
Таш өстендә таш калдырмый
Барсын таптап китәргә». –

(Таҗи Гыйззәт. Ташкыннар. – Казан, 1985. – Б. 348).

Күренә ки, бу мисалларда әйтелмәнең җимерү, туздыру дигән туры мәгънәсе өстенлек итә. Әмма кайбер очракларда ул тулысынча күчерелмә мәгънәдә файдаланылырга мөмкин. Әйтик, Фатих Хөсни, «Утызынчы ел» романын үзенең элегрәк дөнья күргән «Җир тыңлый» исемле әсәренә нигезләнеп язуы турында сөйләп, болай ди:

«Әлбәттә, элеккеге китаптан монда таш өстендә таш та калмады. Ләкин шул ук вакытта искене сүткәндә шундый ташлар да килеп чыккалады, мин аларны бүген, андый чын җемелдәүләре белән, белмим, таба алган булыр идемме икән? Андый «таш»лар, әлбәттә, бүгенге төзелешкә бик ярап куйдылар» (Утызынчы ел. – Казан, 1980.– Б. 6).

Чәршәмбе – иң авыр көн

Галимнәр, интернетта көндәлек алып баручыларның язмаларын тикшереп, атнаның иң авыр көнен исәпләп чыгарган. Тикшеренүчеләр блогтагы сүзләрнең эмоциональ бизәлешен ун баллы шкала буенча бәяләгән. Мәсәлән, “сөенеч”, “бәхет”, “ирекле” кебек сүзләр 8 балл, “хыянәт”, “рәхимсезлек”, “куралмыйм” кебекләре исә 2 баллга гына бәяләнгән. Авторлар бөтендөнья челтәреннән барлыгы 2,4 миллион көндәлекне тикшергән. Күңел төшенкелеген күрсәткән сүзләрнең аеруча чәршәмбе көнне күп кулланылуы ачыкланган. Иң шатлыклы көннәр – шимбә һәм якшәмбе, аннан соң – дүшәмбе (ә без аны иң җайсыз көн дип сүгәргә күнеккәнбез!) Галимнәр болай аңлата: ял көннәрендәге уңай кичерешләр атна башында саклана әле, тора-бара исә алар һаман кими бара. Шулкадәр күп кеше катнашында тикшеренүнең моңарчы үткәрелгәне дә булмаган, шунлыктан аның нәтиҗәсе чынбарлыкка якындыр, мөгаен.

(“Daily Mail”).

Кара... агарган

